Әй, тукта, син кем әле?!

Кеше үзенең хәерчелеге белән дә, ямьсезлеге белән дә, булдыксызлыгы белән дә, кыскасы, кеше үзенең бөтен җитешсезлекләре белән дә килешергә мөмкин. Үзеңнең кимчелекләреңне бит ул! Иң сөекле, иң сөйкемле кешенеке. Аны ничек гафу итмисең ди! Әмма адәм баласы башкаларның байлыгын, матурлыгын, уңганлыгын гына кичерә алмый. Бүтәннәрнең уңышы аны мәсхәрәләп торган кебек була.

4 БИТ

«Бабам патша кучеры булган»

Шәрифулла бабай 1843-1917 елларда яшәгән. Аның бөтен тормышы армия белән бәйле. Ул заманнарда солдатлар 25әр ел хезмәт итә торган булган. Бабай да Александр патшаның кучеры булып хезмәт иткән. Һәрвакытта да башына түбәтәй киеп йөргәнгә, бер дә салмаганга, аның кушаматы Татарин булган. «Семь покушений на Александра второго» дигән фильмда Александр IIнең кучеры – безнең бабабыз турында да искә алына.

10 БИТ

1990 ЕЛДАН БИРЛЕ ЧЫГА

Шәһри КАЗАН

татмедиа

Җомга | 20.01.2017 | № 5 (5767)

www.shahrikazan.com

ТАТАРСТАН БАШКАЛАСЫНЫҢ КӨНДӘЛЕК ИҖТИМАГЫЙ-СӘЯСИ ҺӘМ МӘДӘНИ ГАЗЕТАСЫ

БЕРЕНЧЕ КЫЮ «КОЙМАК»

«Шәһри Казан» газетасының алдагы саннарында Рабит Батулланың Татарстанның Беренче Президенты Минтимер Шәймиевкә багышлап чыгарылган «Илбашы» китабы турында мәгълүмат җиткергән идек инде. Шушы көннәрдә исә әлеге хезмәт киң җәмәгатьчелеккә тәкъдим ителде.

Зөһрә САДЫЙКОВА

tatar-inform.ru

– Документлар туплау бик үк кыен булды, дип әйтмәс идем, чөнки Минтимер Шәймиев турында бик бай материал бар. Үзе белән дә сөйләштек. Без аның белән 90-нчы еллардан бирле таныш. Ирек мәйданында кулга микрофон тотып, «Азатлык!» дип кычкырып йөргән вакытлардан ук. Ул елларда мин урамда булган вакыйгаларны, андагы хәлләргә халык фикерен яздырып, 50-60 кассета туплаган идем. Китап язганда алардан да файдаландым. Аннан соң Беренче Президентның гаиләсе, тормыш иптәше белән мөнәсәбәтләре турындагы өлешләрен язганда, Сәкинә ханымның китабы да ярдәм итте. Әмма әдәби әсәр язу, аны хикәяләр дип атау – анысы катлаулырак булды. Бу, жанры буенча, әдәби-документаль әсәр. Күрәсең, мондый жанрдагы әсәрләр иҗат итү минем өслүбемдер, – дип җавап бирде китапның авторы, халык язучысы Рабит Батулла журналистларның китап язу тарихына кагылышлы соравына.

Шулай ук яшь язучыларга:

– Сюжет таба алмыйча йөрсәгез, тарихка керегез. Беренчедән, халыкны тарих белән кызыксындырырсыз, икенчедән, әдәби образ ясарсыз, – дип, киңәшен дә биреп куйды.

Татарстан китап нәшрияты генераль директоры Илдар Сәгъдәтшин хәбәр иткәнчә, «Илбашы» китабы нәшрият кибетләрендә 2000 данә тираж белән тәкъдим ителгән. Бәясе исә – 180 сум. Киләчәктә аның электрон вариантын да укып булачак. Журналистлар арасында «Ни өчен китап шулай аз тираж белән басылган?» дигән сорау да яңгырады.

– Безнең максат – коммерцияле булган проектлардан тиз арада акчаны кире кайтару. Бу яңа проектлар өчен кирәк. Шуңа күрә әгәр шушы тираж сатылып бетә икән, без аны өстәмә тираж белән дә чыгарта алабыз, – дип аңлатты Илдар Сәгъдәтшин.

Нәшриятның матур әдәбият редакциясе мөдире Газинур Морат әйтүенчә, халык арасында документаль-әдәби әсәрләргә кытлык бар. Монысы да тиз арада сатылып бетәр, дип өметләнә ул. Ә инде китапны әзерләү мәсьәләсенә килгәндә, Газинур әфәнде болай диде:

– Бу китап – беренче «коймак». Минтимер аганың үз ана телендә татарча уйлап, татарча иҗат ителгән беренче әсәр. Моңарчы әле Татарстанда Беренче Президентыбыз турында үз туган телебездә язылган әдәби әсәр юк иде. Халыкның күз өстендәге кашы булган кеше турында китап язу – үзе бер кыюлык, дип саныйм. Әсәрдә моңа кадәр без белмәгән кызыклы да, гыйбрәтле дә булган фактлар күп. Болар аеруча Минтимер аганың бабасы, әтисе язмышында чагыла.

Китап табадан төшеп, укучы хөкеменә тәкъдим ителгәнче үк, әсәрнең төп герое тарафыннан берничә мәртәбә укылган инде. Һәм укылып кына калмыйча, җитди төзәтмәләр дә кертелгән.

– Минтимер Шәймиев иң беренчеләрдән булып караламасын укып чыкты. Һәм аның икенче яртысын ул кире борды. Дөреслектә, аның киңәше бик дөрес булды. Караламаны берничә кат укып чыгып, бастырырга ризалык биргәннән соң да әле тәнкыйть сүзләрен җиткерде. Һәм бик дөрес тәнкыйтьләр бар иде анда. Ул бер яктан икенче якка бәргәләнми – төгәл кеше. Дөресен генә әйткәндә, бу эшкә бик куркынып алынган идем. «Казан утлары» журналыннан тәкъдим килгәч, мин тешем-тырнагым белән каршы булдым. Ләкин Илфак Ибраһимов «салпы ягыма салам кыстырып», «синнән башка кеше яза алмый моны» дигәч, бу эшкә Аллага тапшырып алындым. Һәм тулы бәяне, укып чыккач, укучы әйтер, – диде Рабит Батулла.

Теманың дәвамы 6-8нче битләрдә.

kremlin.ru

Ил җитәкчелеге Минтимер Шәймиевне юбилее белән котлады

Россия Президенты Владимир Путин белән премьер-министр Дмитрий Медведев Татарстанның Беренче Президенты, Дәүләт Киңәшчесе Минтимер Шәймиев белән очрашып, аны юбилее белән котладылар.

– Элеккеге еллардагы уртак хезмәтебез һәм хәзерге вакыттагы уртак мәдәниятебезне һәм тарихыбызны өйрәнүдәге эшләрегез өчен Сезгә рәхмәтемне белдерәм, – дип, Владимир Путин Минтимер Шәймиевкә XVII гасыр картографы, голландияле Виллем Блауның борынгы Тартария картасын бүләк итте.

Республиканың тарихи һәм мәдәни истәлекләрен торгызу буенча «Яңарыш» фонды попечительләр советы рәисе Путин белән Медведевка Изге Мәрьям ана иконасы соборын торгызу һәм Болгар ислам академиясен төзү буенча алып барылган эшләр турында сөйләде.

Исегезгә төшерәбез, 2016 елда Изге Мәрьям ана иконасы соборы нигезенә беренче таш һәм капсула салу тантанасы булды, анда Мәскәү һәм бөтен Русь патриархы Кирилл катнашты. Ул 1932 елда җимерелгән соборның оригиналы буенча торгызыла.

Болгар ислам академиясен 2017 елның язында төзеп бетерү күздә тотыла. Әлеге югары уку йорты татар дин гыйлеме мирасы традицияләрен дәвам иттерәчәк һәм илнең әйдәп барган дини-мәгърифәти һәм рухи-агарту үзәге булачак.

«Татфондбанк» һәм «ИнтехБанк» кертемчеләренә 50 млрд сум акча түләнелгән

Татарстан Икътисад министрлыгы белешмәсе буенча, «Татфондбанк»ка акча салганнарның 119 меңнән артыгы 40 млрд сумлап иминият акчасын алган: бу – түләнергә тиешле иминият акчаларының 78,6 проценты, дип хәбәр итә «Татар-информ».

«ИнтехБанк» кертемчеләренә исә 10 млрд сумнан артык акча түләнелгән, бу шул рәвешле түләнергә тиешле акчаларның 86,8 процентын тәшкил итә. «ИнтехБанк»ның барлыгы 19 меңнән артык клиенты акча алган.

«Татарстан Республикасы Эшкуарлыкка ярдәм фонды» коммерциячел булмаган оешмасына «Татфондбанк»та акчалары тик ятарга мәҗбүр ителгән эшкуарлардан, ташламалы шартларда микрозайм алуны сорап, 161 гариза килгән. Гаризаларда күрсәтелгәннәрнең суммасы 241 млн 512 мең сум тәшкил итә. Эшкуарлыкка ярдәм фондына «кайнар линия» буенча 1776 эшкуар мөрәҗәгать иткән, шул исәптән 1088е – ташламалы шартларда микрозайм алу мәсьәләсе буенча.

Исегезгә төшерәбез: 2016 елның 14 декабрендә «Татфондбанк» клиентларына банкоматлар аша хисап-касса хезмәте күрсәтүне туктатты һәм акча салдыруга чикләү кертте. Икенче көнне Үзәк банк кредиторлар таләпләрен канәгатьләндерүгә мораторий кертте һәм Татфондбанкка вакытлыча администрация билгеләде. Элеккеге административ органнар вәкаләтләре туктатылды. Кертемнәрне иминиятләштерү агентлыгы моны иминият очрагы дип таныды. 21 декабрьдә агентлык банк-агентлар сыйфатында 5 кредит оешмасын сайлап алды: Саклык банкы, «ВТБ 24» банкы, Россельхозбанк, «ФК Открытие» һәм «Ак Барс» банклары. «Татфондбанк» кертемчеләренә шулар аша акча 26 декабрьдән түләнә башлады. Банкта акчалары тик торырга мәҗбүр ителгән эшкуарларга ярдәмгә Татарстан Президенты Рөстәм Миңнеханов йөкләмәсе буенча республика Икътисад министрлыгы карамагында эшче төркем оештырылды.

Калган эшкә кар ява... экологлар штраф сала

Кичә Татарстанның Экология һәм табигый байлыкларны саклау министрлыгы белгечләре Казанның Совет районында тиешсез урыннарда ташланган кар өемнәрен тикшерде. Карны законсыз чыгарган мондый чүплекләр Татарстан буйлап 50гә җитә икән.

Юл буйларында, ишегалларында, су саклау зоналарындагы комлы-тозлы кар өемнәре закон бозу булып санала. Кар махсус урыннарда гына җыелырга тиеш. Казанда андый 20 мәйданчык бар: шуларның алтысы – кар эретү станциясе, ундүрте – кар чүплекләре.

Татарстанның экология һәм табигый байлыкларны саклау министры Фәрит Габделганиев сүзләренчә, тиешсез урынга чүп ташлау проблемасы бөтен республика буенча таралган.

– Карның инде күптәннән яугәны юк, ләкин кар өемнәре әле дә җыелмаган, – дип төртеп күрсәтте министр Себер тракты урамында урнашкан Кузов төзекләндерү үзәге тирәсендәге берничә метр биеклектәге кар өеменә.

– Кар өемнәрен юл буйларына чыгару, ишегалларында җыю, кая да булса яшерергә тырышу – шәһәр төзекләндерү кагыйдәләрен үтәмәү дигән сүз. Җыелган кар аркасында яшел үсентеләр дә, су объектлары да зыян күрә. Без көндез генә түгел, төннәрен дә рейдларга чыгабыз. Закон бозучыларның исемлеген, кышкы сезон тәмамлангач, үз сайтыбызда элачәкбез, – диде Фәрит Габделганиев.

Экологлар исә кар өемнәрен экспертизага алды. Кар гына түгел, анда җыелган ком, тоз, машина газлары да әйләнә-тирәгә зур зыян сала икән. Закон бозучыларны экологлар административ җаваплылыкка тартачак.

Шулай ук рейд барышында экологлар «Техстрой» полимер торбалар төзү заводының машина туктаулышы тирәсендәге кар өемнәрен тикшерде. Биредәге кар Нокса елгасына зыян сала икән.

Синоптиклар хәбәр итүенчә, бу көннәрдә Татарстанда кар явачак. Бу исә экологлар тагын көн-төн рейдлар белән йөриячәк дигән сүз. Тиешсез урында кар өемнәре яту турында хәбәр биргән кешегә министрлык акча түләячәк. Мәгълүмат Telegram һәм WhatsApp кушымталарыннан кабул ителә.

vk.com

«Чемпионат эшче һөнәрләргә мөнәсәбәтне үзгәртте»

«WORLDSKILLS» КӨНДӘЛЕГЕ

1-3 февраль көннәрендә Казанда «Worldskills» стандартлары буенча «Яшь белгечләр» республикакүләм эшче һөнәрләр чемпионаты була. Шул уңайдан һөнәри уку йортлары җиң сызганып эшкә кереште. Җиңүчеләрдән «Worldskills Russia» чемпионатына Татарстан командасы тупланачак.

Алисә САБИРОВА

Илдар Мөхәммәтҗанов фотосы

Катнашучылар арасында медицина, лазер технологияләре, робот техникасы белән эш итүчеләр, пешекче, токарь, ташчы кебек эшче һөнәрләрен очратырга була. Аларның гамәли белемнәрен эш барышында сынаячаклар. Мәсәлән, юл төзүчеләр, Европа стандартларына туры китереп, республиканың берәр федераль трассасында асфальт салачак.

Чаллы шәһәренең политехника көллияте исә чемпионатка төрле компетенция буенча җиде кеше әзерли. Бу уку йорты, республикада беренчеләрдән булып, студентларын «Worldskills» стандартлары буенча укыта башлады. Чемпионатта инде дүртенче ел катнашалар алар. Алдагы елларда Россия буенча II-III урыннар яулаганнар.

– Студентыбыз Антон Лоскутов 2015 елда Финляндиягә барып кайтты, соңыннан ил данын Сан Паулу шәһәрендә яклады. Хәзерге вакытта ул – Мәскәүдә «Worldskills» чемпионатының токарь эшләре буенча эксперт урынбасары. Бу чемпионат ярдәмендә, халыкның эшче һөнәрләренә карашы үзгәрде. Бүген сәнәгать өлкәсендә, заводларда нәкъ менә эшче яшьләр җитми бит. Көллияткә укырга керергә теләүчеләр саны да елдан-ел арта. Студентларыбыз эшкә йөз процент урнашып бара, чөнки алар инде укыган вакыттан ук «КАМАЗ», «Татэлектромаш» кебек төрле оешмаларда тәҗрибә туплый, – диде Чаллы шәһәренең политехника көллияте директоры Илдар Ганиев.

Түбән Кама шәһәренең агросәнәгать көллияте исә чемпионатка белгечләрне өч юнәлештә әзерли. Җиңел автомобильләр ремонты һәм техник хезмәт күрсәтү, ягып җылыту һәм сантехника, төзелешнең коры алымы һәм штукатурлау компетенцияләренә өйрәтә алар студентларын. Укучылары инде Ульяновск, Тольятти, Самара, Саранск, Тамбов, Мәскәү, Красноярск шәһәрләрендә узган төрле чемпионатларда үз көчләрен сынап карарга өлгергән. Көллиятнең зур җиңүләре – автомеханика юнәлешендә.

– Ел саен студентлар арасында ярыш көчәя, белем бирү учреждениеләре балаларны сыйфатлырак укыта. Яңа алымнар, яңа технологияләр кулланалар. Без исә ярышларда 2012 елдан катнашып киләбез. Студентлар да, укытучылар да «Worldskills» кебек ярышларның кирәклеген аңлады. Ләкин бу омтылыш оешмаларга әле барып җитмәде. Безнең белгечлек буенча эш хакы кечкенә. Сәләтле, квалификацияле кеше андый хезмәт хакына бил бөгәргә теләми. Бигрәк тә төзүче, сантехникларның дәрәҗәсен күтәреп булмый. Хезмәтләре авыр, бәяләнми. Токарь, фрезерчы һөнәрләренә яхшы хезмәт хакы түлиләр менә. Бала тырыша, төрле бәйгеләрдә урыннар ала икән, аның бәясе дә шуның кадәр булырга тиеш, минемчә. Дөрес, егетләр югалып калмый. Бер укучыбыз Максим Владимиров төзелешнең коры алымнары компетенциясе буенча Германиядәге ярышларда катнашты. Армиядән кайтканнан соң, үз оешмасын ачарга хыяллана. Россия чемпионатларында беренче урыннар яулаган Андрей Казаньков исә үз тырышлыгы белән автосервис ачып җибәрде. Күпләр машинаны нәкъ менә аңарда төзекләндерү өчен чират тора, – ди Түбән Кама агросәнәгать көллияте директоры Алмаз Кадыйров.

«Worldskills» ярышларының төп өлеше Казан ярминкәсе мәйданында булачак. Шулай ук Казан элемтә техникумы, Казан төзелеш көллияте, МЧС көллиятендә берничә компетенция буенча көч сынашачаклар.

2017 елның октябрь аенда Абу Даби шәһәрендә «Worldskills» дөнья чемпионаты узачак. 2019 елда исә бу чемпионатны Казан каршы алачак.

ТӨЗЕЛЕШ

Тамак туйгач биергә була

Татарстанда агрохуҗалык булып гомер кичерүче авыл кешеләреннән көнләшеп үлмәле. Алар «агрохуҗалык» исеме астында колхозны, ягъни күмәк хуҗалыкны саклап калдылар һәм тормыш-көнкүрештә дә, икътисадта да яңа үрләр яулыйлар.

Узган ел, мәсәлән, агрохуҗалыклы районнардан: Балтачта – 59, Сабада – 52, Минзәләдә – 42, Арчада – 40, Әтнәдә – 39 һәм Азнакай белән Актаныштa 30ар абзар капиталь төзекләндерелгән. Силос яки сенаж салу өчен Кукмарада – 40, Сабада – 27, Балтачта – 25, Әтнәдә – 21, Актаныштa – 20 һәм Биектауда шулай ук 20 траншея төзелгән.

– Татарстанда 2014 елдан башлап, сыер абзарларын капиталь төзекләндерү һәм траншеялар казу буенча республика программасы гамәлгә ашырыла. Өч елда 4,5 миллиард сумга 830 абзар яңартылды. Әлеге эшләргә Татарстан бюджетыннан 1,2 миллиард сум күчерелде. Абзарларның күбесе – узган гасырның 70нче һәм 80нче елларында төзелгән корылмалар. Төзекләндерелгән абзарлар, әлбәттә, хезмәт шартларының яхшыруына да, терлекләр санының артуына да этәргеч булды, – диде Авыл хуҗалыгы һәм азык-төлек министрлыгының инвестиция сәясәте һәм максатчан программалар бүлеге җитәкчесе Илдар Гафуров матбугат конференциясендә.

Республикада быел сыерлар өчен янә 331 абзар капиталь ремонтланачак, 127 силос-сенаж траншеясы төзеләчәк. Программа кысаларында Татарстан бюджетыннан да абзарларны төзекләндерүгә – 470,6 миллион сум, ә траншеялар төзелешенә 61,3 миллион сум билгеләнгән.

Матбугат конференциясендә сүз авыл клублары төзелеше турында да барды. Татарстанда «Авыл клубы» республика программасы нигезендә 2012 елдан башлап 271 клуб төзеп, файдалануга тапшырылган.

– Программа дәвам итә, быел 31 мәдәният бинасы төзеләчәк. Ләкин моннан ары яңа бианалар төзү түгел, ә булганнарын капиталь төзекләндерү буенча эшләячәкбез. Клублар янәшәдәге ике-өч авылга хезмәт күрсәтү күзлегеннән чыгып төзелде, – диде республиканың төзелеш, архитектура һәм торак-коммуналь хуҗалык министры урынбасары Илшат Гыймаев.

Балык Бистәсе районындагы Ямашта яңа клуб төзелгәч, авыл яктырып-балкып китте. Министр урынбасары сүзләрендә хаклык бар: Ямаш клубына концерт һәм театрларга күршедәге Балтач белән Күки кешеләре дә җыела. Хәзер бу авыллар асфальт юл белән тоташкан, машиналарын кабызалар да, әйдүк, театрга. Балтачның клубы иске булса да эшли әле, үзләрендә дә мәдәни чаралар гөрли. Кызганыч, Күки авылы клубы җимерек. Авылдашларны куанычлы хәбәр белән сөендереп булмады.

– Күки авылында клуб төзелеше быелгы планда юк, – диде Илшат Гыймаев.

Дамир БӘДРИЕВ.

Хаҗга барасың киләме?

Әгәр шулай икән, 4 февраль көнне Азнакайда узачак Коръән уку буенча республика бәйгесендә катнашып көчеңне сына.

Бәйгедә республиканың барлык район һәм шәһәрләреннән килгән ир-атлар Коръәнне дөрес итеп укуда үз осталыкларын күрсәтәчәк. Конкурсның шартларына килгәндә, яшь буенча чикләүләр юк. Чарада Татарстан мөфтие Камил хәзрәт Сәмигуллинның да катнашуы көтелә.

– Бәйгенең максаты – Коръәнне өйрәнүгә булган омтылышны тагын да көчәйтү, динебезгә мәхәббәт тәрбияләү. Җиңүчеләргә зур бүләкләр каралган. 1нче урынны яулаучыга эшмәкәр Шакировлар гаиләсе олы хаҗга юллама бүләк итәчәк. 2нче урынга – гомрә хаҗына юллама каралган. Өченче урынны алучы шулай ук кыйммәтле бүләкләр көтә, – ди Азнакай шәһәре мөхтәсибе Азат хәзрәт Талибуллин.

Әй, тукта, син кем әле?!

САКАЛЛЫ КЕШЕ ЯЗМАЛАРЫ

Марат КӘБИРОВ

Никахсыз туган бала сыманрак бер нәрсә инде ул үзе. Аны барысы да яшерергә, кешегә күрсәтмәскә тырыша: «Миндә андый нәрсә булмады, юк һәм булмаячак та!» – дип җиппәрә. Ә ул бар. Һәр кешедә бар. Кайчагында барлыгын сиздерми, кайчак кыткылатып кына тора, кайвакыт давыл куптара. Һәм кеше шул давылны да яшерергә, хәтта иң якыннарына да күрсәтмәскә җан тырмаша. Күрсәтергә ярамый. Мактаулы нәрсә түгел бит.

Сүз көнчелек турында. Моның юньле нәрсә түгел икәне көн кебек ачык инде. Дөньяда көнләшүдән дә начаррак нәрсә юктыр да шикелле. (Сүз, әлбәттә, ир белән хатын арасындагы мөнәсәбәтләр турында гына бармый.) Шул көнчелек аркасында каза күргән кешеләр дә чамасыз. Һәм аның кире сыйфат булуын, беркайчан да, бер эштә дә ярдәм итмәвен һәркем белә. Һәм ул рәхәтләнеп яши бирә.

Минем беркайчан да көнчелекнең файдасы турында укыганым юк. Бер әсәрдә дә. Бөтен язучылар да аңа каршы. Әмма иҗат кешеләре арасына килеп керсәң, көнчелекнең иң хәйран үрнәкләрен күрергә мәҗбүр буласың. Шау-гөр килеп сөйләшеп утырган биш кешелек төркем алдында син алтынчы кешене, әйтик, язучыны (чынлап та талантлы язучыны!) мактап кара. «Ну талант инде, малай, кешедә! Язып та карый ичмасам! Аның кебек беркем дә булдыра алмый бугай!» – дип җиппәр. Төркем бер мәлгә тынып кала. Шуннан дошмани карашлар сине бораулый башлый. Кемдер теш арасыннан чертләтеп төкереп куя. Кемдер сәбәп табып, читкә борыла. Кемдер сәгатенә карап ала. Туры сүзләргә булса, йөзеңә бәреп әйтә: «Тукта! Нәрсәсе бар әле аның һуш китәрлек?! Кем әле ул?» Һәм шул алтынчы язучының шәхесеннәнме, әсәреннәнме гаеп табып, берәр мисал китерә. Ә син шушы биш кешенең яшерен дошманына әйләнәсең.

Иҗат кешеләрен аңларга да мөмкин. Һәркемнең беренче һәм бердәнбер буласы килә. Кемнеңдер күләгәсендә калырга теләүче юк. Күләгәдә калырга тели торган кавем булса, алар бу һөнәрне сайламас, ниндидер заводта тимер кырыр яки милиция формасы киеп, урам буенда таяк болгап йөрер, һич югы берәр колхозда көтү көтәр иде. Иҗат ул – башлангычы белән үк беренчелеккә, бердәнберлеккә, кабатланмас булуга омтылу. Шуңа да иҗатчыларның бер-берсенең уңышын авыр кичерүе артык гаҗәп түгел.

Үзләре көнчелек утында янып та, әсәрләрендә кешеләрнең шул феноменына «каршы көрәшүләре» дә аптыратмый. Көнчелек ул – үз көчсезлегеңне тану. Ә берәүнең дә, ачыктан-ачык, бөтен галәм алдында: «Мин фәлән язучыдан көнләшәм, чөнки ул миннән күпкә талантлырак та, булдыклырак та», – дип әйтәсе юк. Шуңа берәү дә көнләшүен сиздерергә ашыкмый, көндәшен уздырырга җай чыкканын көтеп яши.

Матбугатта чагылып калган кайбер әңгәмәләрдә: «Миннән нык көнләштеләр. Фәлән-фәлән кешеләр (күп очракта, исемшәрифсез генә, кинаяләп әйтелә) аяк чалды…» – дигән сыманрак сүзләр дә еш ишетелгәләп кала. Бу елмаергә мәҗбүр итә. Үзеңнең бик зур фигура икәнеңне күрсәтергә, мактанырга телисең икән, ник шулай кыланып торырга инде?! Тот та әйт: «Мин әйбәт язучы!» – дип. Беркем дә гаепләмәс, чөнки без барыбыз да үзебезне хәйран яхшы дип уйлыйбыз. Мәсьәләнең тагын бер ягы бар әле, шул көнләшеп аяк чалучы кешеләр дип, гадәттә, иң талантлы һәм иң танылган язучыларны күрсәтәләр. «Ну, Тукай миннән көнләшеп тә карады инде!» – дигән шикелләрәк. Тукай тиклем Тукай көнләшерлек булгач, кемлегемне үзегез чамалагыз инде, янәсе.

Язучылар, иҗат кешеләре турында җентекләп сөйләвем аларның үз даирәмнән булгане өчен генә. Сәясәттә дә, фәндә дә, сәнгатьтә дә тулып ята мондый күренеш. Нинди өлкәне генә алып карасаң да, хәйран калырлык. Һөнәри өлкәләрдә генә түгел, күрше белән күрше арасында да. Ну, матур гына яшәп яткан җиреңнән күршең хан сарае кадәр йорт салып куйды, җилле иномарка алды, хатынына яхшы тун кидерде. Ничек көнләшмисең! Төн йокың кача инде. Моңа кадәр ансыз да яшәдең – бер җирең кителмәде. Ә күрше, юньсез… һәм теге, көнләшүгә чыдый алмыйча, кредитларга керә-керә, мең бурычка бата-бата, дөньясын яңарта. Калышмаска кирәк. Калышмау белән генә чикләнми әле ул, күршесен уздырып та җибәрергә тырыша. Йөрәге янсын юньсезнең, төн йокысы качсын!

Бер карасаң, көнләшүнең файдасы да бар. Ул кешене хәрәкәткә әйди, тормышны алга илтү юлларын эзләргә һәм табарга мәҗбүр итә. Гади генә тормыш белән изрәп йоклап яткан авылда берәү, әйтик, ике катлы матур йорт салып куйды, ди. Халык инде туздырылган кырмыска оясына әйләнә, һәркем калышмаска тырыша. Нәтиҗәдә, бер-ике ел эчендә менә дигән матур авыл хасил була. Көнләшү ул – тормышны алга этәрүче могҗиза. Һәм аның нигезендә беренчелеккә омтылу, уңышка ирешкәннәрне уздырып җибәрү теләге ята. Үз шәхесеңнең зурлыгын исбатларга тырышу.

Шулай гына булса икән… Моңысын «ак көнләшү» дип атыйлар бугай. Ул көчле һәм якты шәхесләргә хас.

Әмма көнләшү дә бер төрле генә булмый. Омтылып-омтылып та беренчелеккә чыга алмасаң нишләргә? Ел буена чаптың, бурычларга батып беттең, ә күршеңнеке кебек матур йорт төзеп куя алмадың. Ә ул, юньсез, барысын да сизеп торды. Хәзер әнә мыек астыннан гына көлеп йөри. «Күрсәтермен әле мин сиңа! Җае гына чыксын әле, ут төртәм дөньяңа!» Үзеңнеке дә көлгә калырга мөмкин анысы… Әмма мондый кинәнеч өчен берни жалкы түгел…

Кеше үзенең хәерчелеге белән дә, ямьсезлеге белән дә, булдыксызлыгы белән дә, кыскасы, кеше үзенең бөтен җитешсезлекләре белән дә килешергә мөмкин. Үзеңнең кимчелекләрең бит ул! Иң сөекле, иң сөйкемле кешенеке. Аны ничек гафу итмисең ди! Әмма адәм баласы башкаларның байлыгын, матурлыгын, уңганлыгын гына кичерә алмый. Бүтәннәрнең уңышы аны мәсхәрәләп торган кебек була.

Бу инде «кара көнчелек» буладыр. Югарырак күтәрелгән кешене ничек булса да бәреп төшереп, үзең өстә калырга тырышу.

Күршесенең йортына ут төртергә теләсә кем булдыра алмый. (Бу – мисал өчен генә, теләсәң, «чибәр кешенең йөзенә кислота сибәргә», «яхшы галимне агуларга», «талантлы язучы өстеннән донос язарга» һ.б. дип укы.) Моның өчен дә күпмедер дәрәҗәдә көчле, тәвәккәл, һич югы сантыйрак булу кирәк. Мондый адымнарга күпләр бармый. Бара алмый. Әмма көнләшә. Шулай булгач, күршеңне куып җитә алмаячагыңны аңлап кул селтәгәч, көнләшүдән туктарга да вакыт бит инде. Юк, туктамый. Көнләшүдән туктау – җиңелүеңне тулысынча тану, бирелү, пленга төшү. Ә аның күңелендә өмет бар әле. Бәлки, күрше мантымаслык чиргә уралыр, бәлки, йортын яшен сугар… Җае чыккан саен гайбәт сатып, күршесенең бәхетсезлеккә юлыгуын көтеп йөри ул. Белмим, монысы нинди көнчелек буладыр. Кулыннан эш килми торган соры кешеләргә хас инде бу. Бәлки, «соры көнчелек»тер…

Рәнҗеш төшү

Казан. Кечкенә генә хастаханә. Бүлмәләр салкын түгел үзе, тик коридорда салкынчарак. Анда төне буе ут яна. Ап-ак урындыкка билдән шәрә бер абзый утырган да бирелеп китап укый. Ниндидер «җиңелчә» нәрсә түгел – Чеховның хикәяләр җыентыгы кулында. Абзый инде илленең шактый «өске ягында», өшеп утырганы сизелеп тора. Янәшәдә генә тәмәке тарту бүлмәсе. Абзый ун минут саен диярлек килеп тәмәке «ата» да, шул бүлмәгә кереп, качып тарткан мәктәп баласыдай, ашыга-ашыга тарта. Аннан тагын китапка ябыша. Тәмләп укыганы сизелеп тора.

Ул чираттагы тәмәке «атырга» килгәч сөйләшеп киттек. Казаннан икән. Гади кебек, тик гыйбрәтле язмыш. Яшьли, яратышып йөргән кызы белән өйләнешкәннәр. Абзый – гомере буе автослесарь. Кулыннан килмәгән эш юк. Начар яшәмәгәннәр үзе, тик абзый ныгытып сала башлаган. Алай үзе хатынга кул күтәрмәгән.

– Нәрсә генә күрсәтмәдем инде мин Полиночкама! – ди ул ачынып, ашыга-ашыга тәмәке суырып. Хатын-кыз түзем, тик ул да мәңгелек түгел. Болар 20 еллап яшәгәч, йөрәк авыруыннан хатыны вафат булган абзыйның. Үз балалары булмаган, балалар йортыннан алган бер малай гына калган абзый белән.

– Шуннан соңгы берничә ел тормышымны бөтенләй хәтерләмим – айнымадым, – ди Сергей дәдәй.

Ләкин ир-ат гомер буе ялгыз яши алмый. Үз йорты белән яшәүче Сергей көннәрдән бер көнне яшь хатын алып кайткан.

– Ул хатынның баласы бар иде инде. Аның белән бергә яшәүче энесе дә ияреп килде. Әле бит үзебезнең асрамага алган Вадим да бар. Башта матур гына яшәдек кебек. Аннан башланды. Дөресрәге, үземнең өйдә миңа урын калмады. Кичләрен эштән соң китап укый идем мин аек чакта. Утны күп бетерәсең, дип, аны да тыйды, имеш, тәмәкегә дә акчаны күп бетерәм. Бер яклап – шул. Икенче яклап, Вадим өйләнде, аның хатыны да шундый ук. Инде акчаны да аз эшләмим кебек, аларга һаман җитми. Эштән кайтмыйча, салып, шунда гына калгалый башладым. Өйдә тәмуг! Беренче хатыным Полинаның каргышлары төште бугай… Монда рәхәтләнеп ятам мин…

Абзыйның нигә төннәр буе китап укыганын да, күпләп тәмәке тартканын да аңладым шикелле.

Сергей дәдәй белән сөйләшкәннән соң да шуны уйлап утырам – үз гомер юлыбызда без, аны-моны уйламыйча, күпме кешене, күпме якыннарыбызны рәнҗетәбез. Ә шул рәнҗешләрнең кире кайтуыннан курыкмыйбыз. Ә куркырга кирәк…

Илфак ШИҺАПОВ.

Яшьләр хакимияте эшкә керешге

Татарстанда хәзер бер министрлыкта ике министр булачак. Моның сере бик гади – моннан бер ай элек, 28 декабрьдә, республикада Яшьләр хакимияте оешты. Экология һәм табигый байлыклар министрлыгының ике җитәкчесе очрашып планнарын барлады да инде.

tatarstan.ru

– Республикада Татарстан Президенты Рөстәм Миңнеханов җитәкчелегендә ел саен «Кадрлар резервы» бәйгесе уза. Биредә катнашырга теләүчеләр күп, ел саен меңнән артык гариза килә. Ләкин без бары 140 кешене генә сайлап алабыз да ел әйләнәсендә укытабыз. Әлеге бәйгенең финал өлеше – «Вверх» бәйгесе. Монда җиңгән кеше элек министрлыкларда һәм ведомстволарда стажировка уза ала иде. Хәзер исә без үзебезнең яшьләр хакимиятен булдырырга уйладык. Яшьләрнең акылын, потенциалын республикабыз үсешенә юнәлтәсебез килә. Ниятебезне Татарстан премьер-министры Илдар Халиков та хуплады, – диде «Кадрлар резервы» башкарма директоры Андрей Петухов.

Министрлар җитәкчелек эшенә ике елга сайлана. Яшьләр хакимиятенең экология һәм табигый байлыклар министры дип Дмитрий Моратов сайланды. Аның «Яшел фитнес» проекты турында ике ел элек язган идек инде. Үз теләге белән башлаган проектына ул кыска гына вакыт эчендә 50 мең кеше җәлеп итә алды. Яз-җәй айларында Казан, Әлмәт шәһәр халкын паркларда физкультура ясатты. Хәзер исә спортка мәхәббәтен «Яшел Татарстан» дигән экологиягә багышланган проектта чагылдырмакчы.

– Экология елында бу эшкә төптән алынырга кирәк. Шуңа да без «Юл картасы» төзедек. Беренче төп проблемабыз – су ресурсларын чамадан тыш куллану. Командабыз белән, һәр гаиләгә кранга сенсорлы датчик урнаштырырга тәкъдим итәбез. Бу суны 30-60 процентка экономияләргә ярдәм итәчәк. Ә сайтыбызда исә датчик куйган һәр кешегә бүләк уйнатачакбыз. Икенче проблема – экологик белем бирү. Мәктәпләр буенча экологик спектакльләр оештырып, аларны төрле биремнәр белән ярыштырмакчыбыз. Яз-җәй айларында «Яшел фитнес» проектында халыкны спорт белән шөгыльләнергә генә түгел, ә әйләнә-тирәне сакларга да өндәячәкбез. Өченче төп проблема – атмосфера пычрануы. Без, яшьләр хакимияте вәкилләре, һәрберебез шәһәрдә имән агачлары утыртачакбыз, – дип, еллык эш тәртибе белән таныштырды Дмитрий Моратов.

Дмитрий әлеге проектын экология һәм табигый байлыклар министры Фәрит Габделганиев белән тормышка ашырачак.

– Безнең эшкә яшьләрнең дә кушылуы сөендерә. Иң актив кешеләрне җәлеп итмичә, халык белән эшләп булмый. Яшьләр хөкүмәте формалашуына бер ай да үтмәде әле, ә алар инде төрле кызыклы проектлар белән шакканыра, – диде Фәрит Габделганиев.

Алисә САБИРОВА.

Алар да безнекеләр

Халык телендә аларны төрлечә атыйлар: «гаҗәп балалар», «яңгыр балалары», ә медицинада диагнозлары – аутист. Дөньяда һәр 50 баланың берсе аутист икән. Үз кабыкларына гына бикләнеп яшәүче балаларны җәмгыятьтә югалмаслык үз урыннарын табарлык итеп тәрбияләү, белем бирү – бүген көнүзәк проблемаларның берсе. Татарстан Республикасының Иҗтимагый палатасы үткәргән «түгәрәк өстәл»дә сүз нәкъ менә шул хакта барды.

Әлмәтнең «Гадәти булмаган балалар» иҗтимагый оешмасы вәкиле Андрей Сатыбалов өчен бу тема йөрәк ярасы да, ул үзе шундый баланың атасы. Ләкин һәркем үз сабыеның киләчәген якты итеп күрергә тели. Шуңа күрә дә алар – берничә әти-әни берләшеп, балаларын гадәти мәктәптә укыту мәсьәләсен күтәргәннәр. Шәһәрнең 21нче мәктәбендә аларны тыңлап, хәлләренә кергәннәр.

– Безнеке шикелле балаларның бик күбесе бакчага да, мәктәпкә дә йөрми. Үз эчләренә бикләнгән бит алар, авыр аралашалар. Шуңа да аңлап бетерергә кыен. Әлеге мәктәпнең директорына рәхмәт инде, балаларыбыз өчен махсус бүлмә таптылар. Аларны гадәти балалар белән бер сыйныфта укытып булмый: катырак тавыш та, яктылык та кәефләренә начар тәэсир итә. Шуңа да тирә-яклары капланган махсус парталар кирәк. Бик авырлык белән башлаган эшебез уңай нәтиҗәләрен дә бирә. Хәзер бу балаларның мөстәкыйльлекләре, фикерләү сәләтләре сизелерлек арта башлады, мәктәпкә дә теләп йөриләр, – дип, үзләренең эш тәҗрибәсе һәм кечкенә генә булса да уңышлары белән уртаклашты баласының бәхете өчен кайгыртучы, кул кушырып утырмаучы әти кеше.

Мәскәүдән «Аутизм проблемалары: мәгариф, тикшерү, ярдәм һәм хокук саклау» үзәгеннән килгән Екатерина Мень:

– Аутизм – бик кыйммәт авыру, чөнки аның диагнозын медиклар куя, ә дәвалау, тәрбияләү – Мәгариф министрлыгы өстендә. Бер-берсенә җибәрергә бик җайлы. Өч яшькә кадәр балага бу диагнозны куеп та булмый әле. Аннары да әти-әниләр мондый үзенчәлекле балаларын табибка күрсәтергә бик атлыгып тормыйлар – психиатр дигән сүз куркыта. Ә менә Иркутск өлкәсендә, киресенчә, аутизм диагнозын алыр өчен блат кирәк, ди. Без балаларга гына түгел, әти-әниләргә дә бу диагноз белән ничек яшәргә икәнен өйрәтәбез, аларны бу проблема белән ялгыз калдырмаска тырышабыз. Ләкин бу эштә энтузиазм белән генә булмый, дәүләтнең махсус программасы да кирәк, – диде.

Чаллы шәһәре мәгариф һәм яшьләр эшләре идарәсе җитәкчесе Виннер Харисов Чаллыдагы мәгариф учреждениеләренең мондый балаларга инклюзив белем бирүгә әзерлеге турында сөйләде. Өйрәтүне балалар бакчаларында ук башларга кирәклегенә басым ясады.

– Бүген бу проблемага күз йомып калырга мөмкин түгел. Андый балалар шәхси тәрбиячеләр – тьюторлар ярдәменә мохтаҗ, алар бездә юк дәрәҗәсендә аз, – дип борчылуын белдерде.

Мондый балаларга белем бирүче Чаллы шәһәренең 68нче мәктәп директоры Елена Доценконың чыгышы да кызыклы һәм күпләр өчен үрнәк булды. Әлеге коррекцион мәктәптә 238 бала белем ала, алар арасында аутистлар да бар.

– Без аларны махсус программа белән башта үзебездә укытабыз, гомуми мәктәпләргә җибәрергә дә әзерлибез, – диде ул.

«Түгәрәк өстәл»дә мондый гадәти булмаган балалар язмышына битараф калмаган башка белгечләр дә чыгыш ясады. Баш миендәге нинди дер тайпылышлар аркасында килеп чыга торган, 1943 елда беренче тапкыр телгә алынган әлеге авыру елдан-ел күбрәк балаларыбызны үзенең мәкерле ятьмәсенә ала. Бүгенге «түгәрәк өстәл» республикабызның да андый гадәти булмаган балаларга ярдәм кулын сузарга тырышуын һәм моңа әзер булуын да күрсәтте.

Йолдыз ШӘРАПОВА.

Туган яктан кайткач...

Телебезнең бетүенә, чит мохиттә (ул вакытта мин Удмуртиядә яшәдем) эреп-югалып баруына тирән борчылудан кереп киттем мин иҗатка. Шигырьләрем дә нигездә шул хакта.

Ноябрь аенда үземне Әтнә районының Иске Өҗем мәктәбенә укучылар белән очрашуга чакырдылар. Үзем кайчандыр укыган мәктәп булгангамы, аеруча дулкынланып кайттым, анда алган җылы тәэсирләремнән әле дә булса аерыла алмыйча йөрүем.

Бу матур чараның исеме генә дә күпне сөйли – «Җан җылымны сезгә бирәм». Сценарий авторы – мәктәп китапханәчесе Нәзирә Габдрахманова барысын бер җепкә тезәргә тырышкан. Минем өч җыентыгыма («Күңел дәрьям дулкындулкын», «Без – Можга татарлары», «Шәп абый булам») кергән шигырьләрне файдаланып, искиткеч җылы әдәби-музыкаль кичә оештырганнар. Дистәләгән бала туган як, туган тел, әти-әни, туганнар, дуслык турында шигырьләр сөйләп, горурлык, милләтпәрвәрлек хисләренә баеп, шигъриятнең илаһи дулкыннарында тирбәлделәр. Яшь каләм тибрәтүчеләр – 8нче сыйныф укучылары Галина, Инзилә, Лидия, Зәлияләрнең үзләре иҗат иткән шигырьләрен тыңлау күңелемә аеруча хуш килде.

Безнең заман белән хәзерге заман шартларын чагыштырсаң, аермалар – җир белән күк арасы. Хәзер мәктәп бик матур, заманча җиһазландырылган. Рәшит Хисмәтуллин җитәкчелегендәге коллективның бар тырышлыкларын куеп эшләве, төрле чараларда, конкурсларда катнашып, җиңүләр яулавына да бик сөендем. Кайчандыр без җәяүләп йөргән юлларга асфальт җәелгән, тыз да быз машиналар чабып тора, укучылар мәктәпкә махсус автобусларда килә. Әмма авылларда балалар аз. Шуңа күрә дә күп кенә авылларда мәктәпләр, балалар бакчалары ябыла, клублар бикләнә, хуҗасыз калган өйләр күбәя. Авылда эш булмаганлыктан, яшьләр шәһәргә китү ягын карый, авыл бетә, сүнә. Мондый аяныч нәтиҗә булмасын өчен нишләргә кирәк соң? Авыл яшәргә тиеш бит...

Надия ВӘЛИЕВА,
Казан шәһәре,
162нче балалар
бакчасының татар теле
тәрбиячесе.

Рифкат Вахитов. «Идел-йорт – ил агасы».

Мансур Саттаров. «Минтимер Шәймиев портреты».

ИЛ АГАСЫ

Рәссамнарның Минтимер Шәймиев шәхесенә мөрәҗәгать итүләре очраклы түгел. Халыкның үзеннән чыккан ил агасы булуы өстенә, мәдәниятне, сәнгатьне күтәрүгә гаҗәеп зур өлеш кертүче буларак бәяләү дә әле бу.

Расиха ФӘИЗОВА

– 90нчы елларда мәдәният өлкәсендә булган бөтен реформаларны Минтимер Шәймиев үзе аша уздырды һәм бу өлкәдә әйдаман булды. Франциядә, ЮНЕСКОның штаб-фатирында, Венгриядә, Финляндиядә, Италиядә, Гарәп Әмирлекләрендә, Мәскәүнең Съездлар сараенда узган Татарстан сәнгате күргәзмәләрен ул алып барды, аларга зур импульс бирде. Казан Кремле музей-тыюлыгын, Болгар дәүләт тарих, архитектура музей-тыюлыгын ЮНЕСКО бөтендөнья мирасы исемлегенә кертү, Зөя утраушәһәрчеген торгызу – боларның барысының башында ул торды. Сәяси паритетка, ягъни толерантлыкка нигез салды. Аның исеме мәҗүсилектән алып чыккан Алмыш хан, Рәсәй белән гомерлек солых төзүче шагыйрь, философ, сәясәтче Мөхәммәт Әминнәр белән янәшә тора, – ди әнә сәнгать белгече Розалина Шаһиева да.

Рәссам Әнвәр Сәйфетдинов та, «Борынгы ханнар» сериясен эшләгәндә, Минтимер Шәймиевне юкка гына нәкъ менә Алмыш хан образында бирмәгән инде. Чыннан да, янәшәндә шундый замандашларың булганда, нигә соң әле күктән алып язарга дигән фикерне алга сөргән рәссам.

– Шәймиев Болгарны үзенчә торгызды, шуңа да мин аны Болгар ханы сыйфатында бирдем. 13 ханның портреты керде ул сериягә. Әлеге проект өстендә эшләгәндә, үзем өчен ачышлар да ясадым. Үзебезнең хакимнәребезне, сәясәтчеләребезне белеп тә бетермәгәнмен икән. Әле аларны кулга эләккән очраклы фотолардан түгел, ә күчергечтән (натурадан) эшләсәң һәм һәркайсы белән күзгә-күз карап, һич югы 15 минут утырып сөйләшсәң, гомумән, искитмәле булыр иде, – ди Әнвәр Сәйфетдинов.

Сурәткә алынган геройлар күпвакыт әнә шулай рәссамнарның остаханәсендә үзләрен сәнгать «тәхетенә» утыртуларын белми дә кала. Әмма аларның барыбер кайчан да булса өскә калкып чыгуы, ягъни күргәзмәләргә куелачагы көн кебек ачык.

«Идел-йорт – ил агасы»н да рәссам Рифкат Вахитов башта остаханәсендә эндәшми-тынмый гына эшләсә дә (2010 ел), моннан өч ел элек «Хәзинә» милли сәнгать галереясында 75 яшьлек юбилее уңаеннан узган күргәзмәсендә күрсәтте. Арткы планда хәрабәгә калган борынгы Болгарны, аргамаклар рәвешендә бирелгән чорлар агышын күрсәк, беренче планда акбүз атлар янәшәсендә ил агасы Минтимер Шәймиев сурәтләнә.

– Башта борынгы Болгар ханын ясарга ният бар иде. Соңыннан бүгенге көндә Болгарны торгызуга иң зур көч керткән Минтимер Шәймиев – аның сурәтен эшләргә кирәк дигән нәтиҗәгә килдем, – ди рәссам.

Татарстанның Беренче Президенты Минтимер Шәймиевнең истә кала торган портретлары да шактый. Мондый эшләрне без Мәскәүдә яшәп иҗат итүче Мансур Саттаров, Ильяс Айдаров, Казаннан Зөфәр Гыймаев остаханәләрендә күрә алыр идек. Вакытында бертуган Айдар һәм Нияз Хисамовлар да натурадан эшләгән булган экс-президентның портретын. Хәер, без ул эшләрне моннан берничә еллар элек «Хәзинә» милли сәнгать галереясында узган күргәзмәдә дә күргән идек.

Зөфәр Гыймаев остахәнәсендә.

Автор фотолары

– 2002 елда без дүрт рәссам – Казаннан Григорий Эйдинов белән мин һәм Мәскәүдән ике сынчы – Владимир Демченко, Александр Голобачев – ике көн дәвамында көнгә бер сәгатьтән Минтимер Шәриповичның портретын эшләдек. Аның гына түгел, безнең дә вакыт чикле. Шуңа да бөтен вакытны эшкә багышларга тырыштык. Беренче көнне 20 минут кына эшләдек. Анда да вакыт мәскәүлеләрнең эскизларын карап диярлек үтте. Әлбәттә инде, ара-тирә сөйләшкәләп тә аласың. Минтимер Шәрипович Рәссамнар берлеге турында да сорашты. «Нишләптер син әле «әйе», «юк» кына дип җавап бирәсең», – ди. Ә минем чыннан да иркенләп сөйләшеп торырлык чамам юк. Вакыт бик санаулы. Эш төгәлләнгәч, үзем эшләгән портретка (50х50) бәя дә алдым: «Оригиналга якын эш», – дип бәяләде аны Минтимер Шәймиев. Мин әле моны эшләп бетерәчәкмен дидем, – ди ул чакларны искә төшереп Зөфәр Гыймаев.

Төгәлләп кенә калмый рәссам аны, кабатлап эшли һәм ул эшне рәссамнан килеп алалар. Ә портретның эскиз варианты (рәсемдә) әле дә рәссамның остаханәсендә саклана.

Мисалга Шамил Шәйдуллинның «Казан» милли мәдәният үзәге фондында саклаучы «Казанның 1000 еллыгы» дип аталган монументаль панносын да китерергә булыр иде. Мондый күләмле, күпфигуралы эшне, әлбәттә, күрми калу дөрес тә түгел. Рәссам Абрек Абзгильдин исә Минтимер Шәймиевне «Заман һәм шәхесләр» (2009) дип аталган эшендә Тукай, Мәрҗани, Такташ, Сәйдәшевләр белән бергәттән сурәтли. Биредә Илбашының урыны үзәктә һәм ул аны милли традицияләрне саклап, киләчәк буыннарга тапшыручы шәхес буларак бирә. (Сүз уңаеннан шуынсын да әйтик, рәссамның «Балачак һәм яшьлек арасында» дип аталган эшен Минтимер Шәймиев үзенең кабинетына кабатлап эшләтә.)

Канәфия Нәфыйковның «Хөррият» эше дә чор, заман кыйссасын бәян итә. Азатлыкка сусаган халык, митингка җыелып: «Хөррият!» – дип оран сала. Яңа рухият, мәдәният, әхлак өчен көрәшә халык. Кулларында – китап. Ана телебезне, милли басмаларны саклау мәҗбүриятенә ишарә монысы. Мәчет проектлары да юкка түгел – динебезне, әхлагыбызны кайтарыйк диюе рәссамның. Әлбәттә, шушы мизгелдә иң хәлиткеч сүзне көтә халык. Бу уңайдан ул Минтимер Шәймиевне телеэкранда сурәтли... Әле күптән түгел үзебезнең «ШК»ның күргәзмәләр залында танылган рәссам Озад Хәбибуллинның шәхси күргәзмәсе узды. Ачык китап рәвешендә эшләнеп латуннан коелган «Татарстан тарихының алтын китабы» дип аталган скульптурасында ул шулай ук Минтимер Шәймиевне сурәтли. Эшнең бер ягында аның барельеф-портреты бирелсә, икенче ягында Татарстанның борынгы картасы һәм экс-президентның китабыннан борынгы мирасны торгызуга бәйле өземтә китерелә. Әлбәттә, мондый мисалларны әле тагын да дәвам итеп булыр иде.

...Минтимер Шәймиевнең иҗат әһелләренә мөнәсәбәте мәгълүм. Әгәр дә ул: «Мин үзем шәхсән, теләсә кайсы җитәкчене алыштыра алсам да, иҗат кешесен бервакытта да алыштыра алмыйм, алар – алыштыргысыз», – ди икән, бу инде сәнгать әһелләре эшенә бирелгән иң югары бәя.

– Минтимер Шәймиев – табигатьтән, халыкның үзеннән бирелгән ниндидер бик талымлы зәвык иясе, – диләр рәссамнар үзләре дә.

Хәер, рәссамнар гына түгел, заманында бу хакта Дәүләт Эрмитажының генераль директоры Михаил Пиотровский да бик ачык итеп белдерде: «Минтимер Шәриповичта ниндидер гаҗәеп сизгерлек бар. Әйе, ул мәдәниятне ярата, әмма үзен зур белгечкә санамый, һәрвакыт теге яки бу экспонат турында үз фикерен белдергәндә, бу бары тик аның фикере һәм аның хисләре, дип ассызыклый. Гәрчә аңарда яхшы зәвык һәм аның бәясе нигездә дөрес булса да, ул һәрвакыт үз фикеренә төзәтмәләр кертергә, башкаларның фикерен тыңларга әзер һәм үзенекен көчләп такмый...» Бу кадәресе дә очраклы кузәтүләрдән генә түгеллеген яхшы аңлыйбыз, чөнки заманында Эрмитаж тупланмасы булган Кубрат хан хәзинәсе күргәзмәсен Татарстан башкаласына китертү өчен аз тырышмый Минтимер Шәймиев. Моның өчен иң беренче чиратта дөнья стандартларына туры килгән, ягъни мәсәлән, Лондондагы кебек күргәзмә залы булдыру таләп ителә. Илбашы тотынгач, анысы да тормышка аша. Шулай итеп, Кубрат хан хәзинәсе 1997 елда Казанда күрсәтелә. Алга таба Эрмитажның иярчен үзәген Казанда булдыру идеясен дә Минтимер Шәймиев кузгатып җибәрә. Казанның меңьеллыгына Казан Кремле музей-тыюлыгында ачылган Эрмитаж залы бүген дә казанлыларның, туристларның иң яраткан урыннарының берсе дип әйтә алабыз. Мәдәниятка, сәнгатькә, тамырларыбызга битараф кеше мондый эшкә алыныр идеме?

Минтимер Шәймиевнең оныгы Камилә:

«Дәү әти оныкларын тырыш һәм җаваплы булырга өйрәтте»

Камилә Шәймиеваның шәхси архивыннан

Татарстанның Беренче Президенты Минтимер Шәймиевнең оныгы Камилә Шәймиева дәү әтисенең юбилее алдыннан «Шәһри Казан» газетасына эксклюзив әңгәмә бирде.

– Камилә ханым, дәү әтиегез Минтимер Шәрипович белән бәйле иң якты балачак хатирәләрегезне барлыйк әле.

– Дөрестән дә, балачагымның иң якты, җылы истәлекләре яраткан дәү әтием белән бәйле. Эше никадәр генә тыгыз булса да, ул һәрвакыт минем өчен вакытын таба иде. Мине велосипедта йөртергә өйрәткәнен, шахмат уенының серләренә төшендергәнен хәтерлим. Аның янәшәсендә һәрвакыт бик җылы һәм рәхәт, чөнки ярдәмен һәм кайгыртуын тоясың. Ул күп эшли һәм эшләргә ярата кына калмый, ә физик хезмәт һәм актив тормыш яшәү рәвеше яклы: күп йөзә, чаңгыда шуа, бакчада эшли. һәм һәрвакыт үзе белән мине дә ала иде! Әлеге истәлекләр минем бүгенге тормышымның аерылгысыз өлеше булып тора, моның өчен дәү әтиемә чиксез рәхмәтлемен.

– Минтимер Шәрипович сездә үзегез өчен аеруча кадерле булган нинди сыйфатлар тәрбияләде?

– Әти-әниләрнең һәм әби-бабайларның балага карата әйтелгән «иң акыллы сүзләре» дә мисалларында күрсәткән абруйлары каршында югалып кала. Дәү әти – бәхәссез, авторитет һәм күпләр, шул исәптән минем өчен дә – үрнәк. Акыллы, зирәк җитәкче, уникаль харизмалы, тирән фикерле һәм көчле рухлы кеше. Дәү әтиебез безне, оныкларын, һәрвакыт тырыш һәм җаваплы булырга өйрәтте. Минем өчен аның белән бергә булган вакытлар аеруча кадерле, чөнки әлеге сәгатьләр – акыл-зирәклек һәм кешеләрне, тормышны аның бөтен чагылышында ярату буенча – тормыш дәресләре.

– Камилә ханым, бер ай элек үзегез дә әни булдыгыз. Сезне ихластан котлыйбыз! Дәү әтиегезнең төпле киңәшләрен үз балаларыгызны тәрбияләгәндә дә кулланачаксызмы?

– Әйе, дәү әтиебезнең юбилее алдыннан безнең зур гаиләбездә сөенечле һәм көтеп алынган матур вакыйга булды – аның беренче оныкчыгы туды. Безнең бөек дәү әтиебез оныкчыгын кулларына алып, сөеп яратты инде. Әлбәттә, балабызны тәрбияләүдә аның киңәшләрен һичшиксез кулланачакмын һәм баламны көчле нәселнең лаеклы вәкиле итеп тәрбияләп үстерергә бөтен көчемне куячакмын.

– Дәү әтиегезнең матур юбилее уңаеннан, аңа нинди теләкләр телисез?

– Кадерле дәү әтием, сине үзем һәм гаиләбез исеменнән шундый матур бәйрәмең белән чын күңелдән тәбрик итәм! Беренче чиратта төп тормыш дәресләрең – безгә кылган яхшылыкларың һәм күңел җылың, тормышка булган бетмәс-төкәнмәс мәхәббәтең, зирәклегең һәм нинди генә ситуациядә дә үзеңә генә хас үткен юмор хисең өчен рәхмәтемне җиткерәсем килә. Әлбәттә, сәламәтлек һәм син генә уйлап табарга сәләтле яңа проектларны тормышка ашыруда иҗат дәрте телим. Тагын бер кат рәхмәт сиңа!

«Законда вак-төяк юк»

Рәисә СӘХИЕВА, Татарстан Республикасының Конституция суды рәисе урынбасары:

– Минтимер Шәриповичның бөтен нәрсәдә таләпчән кеше булуын игътибардан читтә калдырырга ярамый – үзенә карата да, җитәкчеләргә дә һәм бөтен түрәләргә дә. Ул һәр мөрәҗәгатьне, документны игътибар белән укый, шуннан соң гына үзенең резолюциясен сала, имза куя иде. Ә Дәүләт Советыннан килгән кануннарны исә һәрвакыт башта, өйрәнер өчен, Татарстан Прокурорына, Министрлар кабинетына, Юстиция, Финанс министрлыгына һәм башка министрлыклар, ведомстволарга җибәрә, алардан уңай нәтиҗә булганда гына имзалый иде. Кайчагында игътибар да итми торган нәрсәләр уңаеннан көтелмәгән сораулар бирә торган иде. «Законда вак-төяк юк, анда һәр сүзгә хокукый мәгънә йөкләнелгән», – дип әйтә иде ул һәрвакыт.

Кануннарда безнең Конституциягә яки федераль кануннарга каршы килердәй нормалар каралган яки бюджетта каралмаган чыгымнар турында сүз барса, ул Татарстан Конституциясенең 79нчы маддәсендә каралган үз хокукыннан файдаланды. Әлеге маддә буенча Татарстан Республикасы Президенты канунны имзалап, халыкка игълан итә яки кергән көннән алып, 14 көн эчендә кире кага. һәм әлеге хокукыннан аңа күп тапкырлар файдаланырга туры килде. Әйтик, Татарстан Дәүләт Советының өченче чакырылышы (2004-2009 еллар) тарафыннан 505 канун кабул ителгән, шуларның 12се кире кагылган. Андый кануннар Дәүләт Советына кайтарыла. Шундый кануннарның берсендә һава өчен түләү кертү турындагы нормалар каралган иде. Парламент вәкилләре белән очрашу вакытында Минтимер Шәймиев: «һавага түләү кертү белән бервакытта да килешмәячәкмен, һава сулаган өчен халык акча түләсенме? Шул гына җитмәгән. Булмаганны!» – дип, әлеге канунны имзаламыйча, республиканың Дәүләт Советына кире кайтарды. Мондый очраклар аз булмады.

«Тузган торак» программасы барлыкка килгән вакытларны да яхшы хәтерлим. Минтимер Шәрипович муниципаль район, шәһәр башлыкларын чакырып, төзелеш буенча зур киңәшмә җыйды. Ул чактагы Казан мэры Камил Исхаков та шунда иде. Минтимер Шәймиев, Камил Исхаковка мөрәҗәгать итеп: «Менә сез Карловы Варыда еш буласыз, карагыз әле, нинди пөхтә, матур йортлар бит анда. Соң без Казанны шулай итә алмаслыкмы? Уйлап карагыз, кешенең тормышы ничек уза?! Алар бит иске йортларда туган, шунда үскән һәм аларның балалары да шул җимерек арасында туа. Безнең халык алай яшәргә тиеш түгел. Әйдәгез, вазгыятьне үзгәртик, тузган торакны бетерү турында программа кабул итик. Финанслау чыганакларын билгеләп, халыкны кая, ничек итеп күчерүне хәл итик», – диде. Шушы киңәшмәдән соң тузган торак программасы буенча эш башланды.

Аның җитәкчелегендә эшләү кызык та, җайлы да иде. һәрвакыт яңа идеяләр, тәкъдимнәр туып кына торды. Аларның һәркайсы киләчәкне күздә тотып эшләнде. Җитәкчене уңайсыз хәлдә калдырмас өчен, һәр эшне тел-теш тидермәслек итеп, законда каралганча, җиренә җиткереп башкара идем. Монысын иң мөһиме дип саныйм. Минтимер Шәймиев кебек зирәк, гадел, ачык, принципиаль, тәҗрибәле җитәкче командасында эшли алуыма язмышыма рәхмәтлемен.

«Ул безнең республика символы»

Зилә СӨНГАТУЛЛИНА, Татарстанның һәм Россиянең халык артисты:

– Шәймиев ул – безнең республика символы. Метро төзелә башлау, «Кол Шәриф» мәчете, Сәйдәшев исемендәге концерт залы дисеңме – һәркайсы аның исеме белән бәйле. Кеше буларак та халыкның хәленә керә белгән җитәкче ул. Бер яктан караганда – ул гади, икенче яктан – шәхес. Аның кебек үзенә алмаш әзерләгән шәхес юк. Дәүләт җитәкчесе сәнгатьне яратып концерт-театрларга килеп утыра, артистлар да үзләрен горур тота. Минтимер Шәрипович үзе дә бик моңлы җырлый. Рөстәм Яхинның «Керим әле урманнарга» җырын яратып башкара. Без «Созвездие – Йолдызлык» балалар фестивален аның белән бергә башладык. Акыллы җитәкче генә алга таба карап, киләчәк буыннарны кайгырта. Хәзер әлеге фестивальне Рөстәм Миңнеханов үз канаты астына алды.

«Кешелеклелеге – тормыштан»

Әнәс ХӘСӘНОВ,
1991-1999 елларда Президентның матбугат үзәге җитәкчесе:

– Ленинның: «Эшләрен белми торып, кешенең кемлеген белеп булмый, белсәң, шул тышкы кыяфәтен генә беләсең», – дигән сүзләре бар. Димәк, кешенең кемлеге аның эш-гамәлләреннән күренә, башкаларга мөнәсәбәтеннән беленә. 20 елга якын Минтимер Шәрипович командасында хезмәт иткәндә, аның йөзләрчә мәртәбә: «Мин кешеләрне яратам», – дигән сүзләренә шаһит булдым. Бу аның тормыш кагыйдәсе, кредосы булуына төшендем. Шушы кагыйдәсен ул ничек тормышка ашырды соң? Башта Югары Совет рәисе, аннан соң Президент булып эшләгәндә, күпмилләтле, күпконфессияле республика статусын союздаш республикалар дәрәҗәсенә күтәрү өчен көрәшү нәкъ шул кредоны тормышка ашыру булды. Татарстанның дәүләт суверенитеты турында декларация игълан итү һәм аның милли төсмере булмаячак, дип аңлату республиканың барлык халыкларын кайгырту иде бит. Татарстан белән Россия арасында шартнамә төзү теоретик һәм практик яктан тиңдәшсез гамәл булып тарихка кереп калды. Базар шартларына «йомшак керү» программасы, тормышта килеп туган кискен сәяси, икътисади кар-

шылыкларны хәл итүдә «Татарстан моделе», халыкны адреслы яклау юлларын табу, һәртөрле мәсьәләләрне халкыбыз белән уртага салып, ачык хәл итү... Боларны саный башласаң, Минтимер Шәймиев кредосының тирән халыкчанлыгы, гуманлыгы ачылганнан-ачыла бара.

Президент аппаратында эшләгәндә, минем янга килгән кешеләр, Минтимер Шәймиевкә һәйкәл салырга кирәк, дигән тәкъдимнәрен әйтәләр иде. Бер мәртәбә мин аңа: «Һәйкәл, әлбәттә, үз вакытында булыр. Халык гасырлар буе хыялында йөрткән «Кол Шәриф» мәчетен торгызу, Чулман аша менә дигән күпер төзү үзе генә дә сезгә һәйкәл салу бит», – дигән идем. Шул чагында ул: «Хикмәт бит һәйкәлдә түгел. Газлаштыру, тузган торакны бетерү программаларын тормышка ашыру да халкыбызның тормыш дәрәҗәсен, яшәү сыйфатын күтәрүдә зур адымнар булды», – диде.

Минтимер Шәриповичның шәхсән үтенечләр белән мөрәҗәгать иткән кешеләрне кире борган очракларын мин хәтерләмим. Мәдәният, әдәбият, сәнгать әһелләренең хатларына җавап әзерләгәндә, ул мөмкин кадәр игътибарлы булырга куша иде. Кешелеклелек сыйфатлары каян килде икән, дип уйлаганда, мин аның кечкенәдән үк өйне кизәк ягып җылытуның, черек бәрәңге белән туклануның нәрсә икәнен күреп үсүеннән, дип беләм. Авыл баласы халык ихтыяҗын күреп үсә шул ул. Халык йөрәге бик сизгер. Ул Минтимер Шәриповичны үз итә. Үз итү төшенчәсе күпкырлы. Аңа ихтирам, хөрмәт, илтифат, ярату мәгънәләре салынган. Аны башка телгә тәрҗемә итү дә авыр икән. Гади генә бу төшенчәдә мин җан якынлыгы, рухи якынлык күрәм. Җитәкче өчен халкың белән әнә шул җан һәм рухи якынлыклардан да кыйммәтрәк берни дә юк бит.

«Шәһри Казан»да – яңа күргәзмә

«Шәһри Казан» газетасы редакциясенең күргәзмәләр залында «Чор һәм шәхес» дип аталган фотокүргәзмә ачылды. Анда фотохәбәрчеләр Илдар Мөхәммәтҗанов һәм Шамил Абдюшевның төрле елларда республика тормышында булган иң җете вакыйгаларны чагылдырган 80 эше урын алды. Авторларның исемнәре республика матбугатын укып баручыларга яхшы таныш. Илдар Мөхәммәтҗановның – 30, Шамил Абдюшевның, һич арттырусыз, 40 еллык тәҗрибәсе бар бу өлкәдә.

– Шәхсән миңа, сүз белән аңлатуга караганда, сюжет белән әйтеп бирү үтемлерәк тоела. Фотода һәркем үзе теләгәнне күрә. Кайчагында башкалар искәрмәгәнне күрсәтәсе килгән чаклар да була. Иң мөһиме, фото ул тарихта истәлек булып кала, – ди мәктәп елларыннан ук кулыннан фотоаппаратын төшермәгән Илдар Мөхәммәтҗанов.

Кайчандыр сөт һәм сөт продуктлары технологы белгечлеге буенча техникумда укып йөргәндер бу егет дип башка да китермисең аның эшләрен караганда. Фотоархивында күбрәк Дәүләт Советы, хөкүмәт эшлеклеләре белән бәйле кадрлар өстенлек итә. Һөнәренә зур әзерлек – башта училище, аннары СССР Журналистлар берлеге каршындагы фотоүзәктә укып килгән кеше буларак, үз эшенең бөтен нечкәлекләрен белә ул.

– Фото эшендә кумирым танылган фотохәбәрче мәрхүм Исмәгыйл Ишмөхәммәтов иде. Үзем исә динамика яратам. Спорт ярышларында булырга, андагы иң хәлиткеч мизгелләрне «тотып алырга» тырышам, – ди журналистларның «Бәллүр каләм» иясе (2007) Шамил Абдюшев.

Текстиль сәнәгате институтын алтынчы курста юкка гына ташлап китмәгән Шамил Абдюшев та. Нәкъ шул вакытта фотоаппарат бүләк иткән аңа әтисе. Шушы фотоаппарат аны армиядә дә, аннан кайткач та иң кирәкле кеше итә. Тора-бара КФУда фотожурналистика серләренә тирәнтен төшенә. Ә инде ишектән кусалар, тәрәзәдән керү серләрен һәр журналистка тормыш үзе өйрәтә.

Шамил Абдюшев фотолары

Расиха ФӘИЗОВА.

Минтимер Шәрип улының 80 яшьлек юбилее алдыннан, карлы гыйнвар көннәрендә, әниемнең сөенечле күзләрен кабат күргәндәй булдым. Гомер буе укытучы булып балаларга математика серләрен өйрәтсә дә, ниндидер зур бүләкләр, исемнәр алган кеше түгел иде. Гади авыл мәктәбенең гади укытучысы булып гомер итте. Шуңа да Президент кадәр Президент кулыннан бүләк-күчтәнәч алгач, кош тоткандай, сөенеп кайткан иде.

Президент күчтәнәче

Оныклары тугач, үзе бер генә кыз үстергән әнием дәү әни вазифасын бик яратып, теләп, тырышып башкара башлады – Сәйдәшне ала да Казан күрсәтеп йөри. Көннәрдән бер көнне болар Татарстан нефтьчеләренең Казанда узган бәйрәм-ярминкәсенә барганнар. Сарман районы Җәлил бистәсендә яшәүче кодасы нефтьче бит (ул да гүр иясе инде хәзер, әй гомерләр!), шуны хөрмәтләптер инде. Цирк алдындагы мәйданда булган ул ярминкә. Табыннарга куелган сый-нигъмәттән өстәлләр сыгылып торган, дәртле көйләр күңелләрен җилкендергән.

Җыелган халык кинәт бер мәлгә тынып калган. Минтимер Шәймиев тә бу бәйрәмне күрергә килгән икән. Аның каршына сәйләнле-чуклы калфаклар, чигелгән камзуллар, балитәкле күлмәкләр кигән сылу кызлар чыгып, күпереп пешкән ак калачлар, таудай өелеп торган баллы чәкчәкләр бирә башлаганнар. Әниемнең Президентны болай якыннан күргәне булмаган. Телевизор экранынннан да шундый ягымлы итеп елмая бит ул, янәшәсендә басып торганда биграк сөйкемле күренгән. Ул арада Минтимер Шәймиев кулындагы чәкчәген әниемә сузган. Үзенә мондый игътибарны, хөрмәтне күрмәгән әнием аптырап калган: алырга да, алмаска да белми икән. Ә ул, әниемнең икеләнүен тәмам юкка чыгарып, тагын да ныграк елмаеп:

– Алыгыз ал, шәхсән сезгә бирәм! – дигән.

Таудай өелеп торган гәрәбәдәй чәкчәкне алганда, әнием, каушаудан, рәхмәт әйтергә дә оныткан. Исенә килгәндә, Президент ярминкә рәтләре буенча алга киткән булган инде. Сәйдәш тә аптыраган: «Шәймиев абый нишләп сиңа чәкчәк бирде?» – дип, юл буе йөдәткән.

Хәер, бу сорауга әни үзе дә җавап бирә алмас иде. Ул бу сорауга аннары да бик озак җавап табарга тырышып карады. Үзенчә фараз да кылды: «Бәлки, ул минем гомерем буе укытучы булып эшләвемне белгәндер, мөгаллимлек кешенең йөзенә чыга бит. Бәлки, кодамның нефтьче булганын сизенгәндер, бәлки, киявемнең үстергән игеннәрне саклап, ил өстәленә ипи итеп менгерер өчен армый-талмый эшләвен белгәндер, бәлки, оныгымда республикабызның киләчәк кешесен күргәндер», – дип фаразлаган иде. Аннары: «Әйе шул, күргәндер, белгәндер, Президент бит ул! Кешеләрнең күңелен аңлый алмаса, сүзләрен тыңламаса, мондый зур ышанычны казана да алмас, илне туры юлдан да алып бара алмас иде. Исән генә булсын, берук!» – дип, үзенчә нәтиҗә чыгарып, озаклап теләк теләп утырган иде әнием.

Әгәр дә исән булган булса, әнием бу хакта Минтимер Шәймиевнең юбилей көннәрендә кабат искә төшерер, чәкчәк пешереп аны котларга да барыр иде. Арабыздан вакытсыз китте шул...

Йолдыз ШӘРАПОВА.



театр-туймазы.рф

Тәгәрмәч өстендәге театр

Камал театрында Туймазы татар дәүләт драма театры гастрольләре булды. Туймазы театры белән Казан тамашачысы таныш инде. Былтыр 25 еллык юбилейлары уңаеннан, аларның Казан, Уфа, Мәскәү шәһәрләре буйлап гастроль турлары узды. Бу юлы да артистларны җылы каршы алдылар.

Алисә САБИРОВА

– Казанга килү рәхәт, шул ук вакытта без зур имтихан тотабыз. Сездә көненә 30лап чара уза. Шуңа да Казан тамашачысы үз бәясен белә, сайлана. Ул күңеленә ятышлы булмаган спектакльне карарга килмәячәк, – ди Туймазы татар дәүләт драма театры директоры Фирзат Габидуллин. – Башкортстан татарлары – дәртле халык. Без тик тора белмибез. Гел тәгәрмәч өстендә, гастрольләргә йөрибез. Шәһәребез бәләкәй, Камал театры кебек, бер спектакльне йөзәр тапкыр уйнап булмый шул. Безнең тел дә үзгә. Камал театрының да, башкорт театрының да үзенчәлекләрен алмыйбыз. Шуңа да татар теленең иң матур үрнәге Башкортстанда сакланган дим мин. Туймазы халкы театрны шулкадәр ярата, бер спектакльне бишәр тапкыр карый алар. Хәтта киенү бүлмәсенә кереп, режиссер белән, нишләп болай иттегез, дип гәпләшәләр.

Тамашаның беренче көнендә башкорт драматургы Ибраһим Абдуллинның «Тиле яшьлек» лирик комедиясе сәхнәләштерелде. Әсәрдә вакыйгалар кечкенә генә бер авылда бара. Уттай печән өсте. Авыл гөрли. Көннәрдән бер көнне яшь белгеч – Сандугач исемле 19 яшьлек агроном кыз кайта. Шул көннән авыл егетләренең тынычлыгы бетә, барысы да чибәр кызга гашыйк булалар. Әсәр уен-көлке белән үрелеп барды. Александр Коровкинның «Түтиләр» спектакле (режиссеры — Зиннур Сөләйсанов) дә тамашачы күңеленә кереп калды.

Роберт Миңнуллин әсәрләре буенча эшләнгән «Каеннарым белән...» исемле музыкаль-шигъри спектакль кече залда булды. Гади тамашачы өчен катлаулы булырга тиешле әсәр бер сулышта каралды. Спектакльнең режиссеры – Башкортстанның һәм Татарстанның атказанган сәнгать эшлеклесе Байрас Ибраһимов шигъри юлларны бер җепкә тезеп, кызыклы сюжет линияләрен уйната алган. Тамашачы Роберт Миңнуллинның балачагына сәяхәт итеп, Сөн буйларында ял итеп, әни кочагында иркәләнеп, каеннар арасында адашып кайтты. Шигырьгә рок-н-ролл биеп була дип кем уйлаган?!

– «Каеннарым белән...» спектакле Әдәбият елында дөнья күрде. Бу – шагыйрь иҗатына үзенчәлекле караш. Спектакльне әзерләгән вакытта, без Башкортстанның Илеш районында булдык, Роберт Миңнуллинның тормыш юлын, иҗатын тирәнтен өйрәндек. Бездә аны бик яратып карыйлар, – диде Фирзат Габидуллин.

Тамашага автор да гаиләсе белән килгән иде.

– Шагыйрь күңеле бик нечкә, аңа күп кирәкми. Бу спектакльне беренче тапкыр карагач, үзем өчен өр-яңа шагыйрь ачтым. Спектакльдән соң үземнең бер дигән әйбәт шагыйрь икәнемне аңладым. Шигырьләрем тамчы да үзгәрмәгән, актерларыбыз да шомарган. Дөресен генә әйткәндә, Туймазыда беренче тапкыр тамашаны карагач, шигъри-спектакль сәхнәдә озак тормас, бер-ике уйнарлар да, артистларның күңеле булыр да, туктатырлар дидем. Ләкин спектакль инде берничә ел сәхнәдән төшми. Димәк, тамашачыга ошый, – дип бәяләде спектакльне Роберт Миңнуллин.

Тамаша залында Камал театры артистлары да бар иде. Үзе дә шигырьләр язучы Татарстанның халык артисты Хәлим Җәләй шагыйрь иҗаты белән дә, артистлар белән дә чиксез соклануын белдерде.

– Мин үз гомеремдә күп кенә шигырь кичәләрендә булдым, ләкин мондый ләззәтне күптән алган юк иде. Күрәсең, мондый жанр яшәргә хаклы. Бүген яшь артистларга карап сокланып утырдым. Һәр сүз, һәр хәреф үз урынында. Җитмәсә барысы да матур итеп җырлый, – диде Хәлим Җәләй.

Коллектив Илгиз Зәйниевнең «Әрем исе» драмасын да тәкъдим итте. Әлеге спектакль Камал театрында да уңышлы гына бара, шуңа да чагыштырлык әйберләр күп булды.

– «Әрем исе»нә курыкмыйча алындык. Бүген бу бик актуаль тема. Адашкан җаннар күп хәзер. Еракка барырга кирәкми, урамга гына чыгасы. Һәр театрның үз йөзе, материаль бирелеше бар, шуңа да Камал артистлары арасында югалып калырбыз дип курыкмыйм, – диде Фирзат Габидуллин.

Сәхнә бизәлеше тыйнак булса да, спектакльнең беренче мизгелләннән артистлар ышандыра алды. Аларның кайгы-борчуларына син дә көенеп, утлыкларына сөенеп утырасың. Юмор хисе белән үрелеп барса да, спектакль җитди, фәлсәфи темаларны күтәрде. Гомер буе үз-үзен эзләп тә таба алмаган адашкан җаннар, тамырсыз, ялгышкан кешеләр җыелган сәхнәдә...

Сәфәр беркемгә һични әйтми, үзеннән бәби көткән кызны, якыннарын, туганнарын калдырып, бәхет эзләп, авылыннан чыгып китә. 35 ел вакыт узгач, берни булмагандай, туган җиренә кайта. Иске генә йортта яши башлый. Тик кемгә кирәк соң ул бүген биредә?! Туган авылының әрем исен сагынып кайткан Сәфәр 35 ел элек кылган гөнаһларын бу юлы да юа алмый, ул кабат кача. Дөрес әйтәләр икән, бары тик көчле рухлылар гына бәхетле була ала. Бәхетле булыр өчен көрәшергә кирәк бит. Бәхетсез булу җиңелрәк. Сәфәр дә җиңел юлны сайлый. Яраткан кешесенә, ярдәм көткән оныгына терәк була алмый.

Камаллылар вариантында спектакльдә режиссер геройларга да, тамашачыга да өмет уты калдырган иде. Физкультура укытучысыннан балага узган Нурзилә җыр-моңга гашыйк, яхшы күңелле егет Сәяр белән бергә калды. Биредә әле якты киләчәккә өмет бар. Ә туймазылылар тәкъдим иткән әсәрдә Нурзилә, әбисен, укырга барам дип алдалап, бала төшерергә калага китеп барды.

«Сәфәр безне ташлап киткәч, безнең нәселдәге хатын-кызларга ялгыз бала үстерү каргышы төшкәндер, күрәсең. Мин бу каргышка нокта куям», – дип китте ул. Бәлки бу адымыннан соң ул бөтенләй ана була алмас?! Бу исә Сәфәрнең дә нәсел җебе корый дигән сүз. Тарих битендә дә, кеше хәтерендә дә ул мәңгегә эзсез югалачак.

Үзләре әйтмешли, күпне күргән Казан тамашачысы артистларга, аягүрә басып, кул чапты.

«Түләк» кабат сәхнәгә кайта

Күренекле композитор Нәҗиб Җиһановны заманында үзе җитәкләгән Казан дәүләт консерваториясендә искә алдылар. Бер төркем сәнгать әһелләре кайчандыр Мәскәүдә ул булдырырга теләгән музыкаль театр турында сөйләштеләр.

– Безнең татар халкы Сәйдәшев, Габәшиләрдән башлап, музыкаль драмаларны ярата. Әйтик, «Зәңгәр шәл» спектакле бүген дә сәхнәдән төшми. Бездә элек опера һәм Камал театры бер бинада эшләгән вакытта «Кандыр буе», «Наемщик». «Башмагым» кебек музыкаль спектакльләр куелган. Әмма опера театры аерым бинага күчкәч, ул традиция югалды. Консерватория каршында эшләп килүче опера студиясе Әлфия Җаббарова җитәкчелегендә студентлар белән опералар куя башлады һәм алар зур уңыш белән узды. Мәсәлән, Кремльдә куелган «Алтынчәч» операсын 5 мең кеше караган. Киләчәктә консерватория каршында музыкаль театр булдыру кирәк, әмма аның өчен бина юк. Башка шәһәрләрдәге зур консерваторияләрнең үз опера студияләренең бианалары бар. Безнең консерватория спектакльләр куярга җайланмаган. Әгәр бина була калса, яшь композиторлар өчен дә иҗат остаханәсе булыр иде, – ди консерватория профессоры Сәгыйть Хәбибуллин.

Катнашучыларның һәркайсы шундый театр кирәклеген ассызыклады. Соңыннан опера студиясе студентлары әзерләгән Җиһановның «Түләк» операсыннан өзекләр башкарылды. Тулысынча ул әсәр 20 апрельдә куелачак. Анда Түләк партиясен Татарстанның атказанган артисты Филүс Каһиров башкара.

Люция ГАЛИМҖАНОВА.

«Бабам патша кучеры булган»

Шәҗәрә төзү – халкыбызның иң матур йолаларының берсе. Чыннан да, һәркем үзенең нәселен белергә һәм кайсы тамырдан булуы белән кызыксынырга тиеш. Без әби-бабаларыбыз алдында аларның чылбырында булган гореф-гадәтләрне, йолаларны буыннан буынга тапшырырга бурычлы.



Без дә үзебезнең нәсел тарихыбызны кызыксынып өйрәндек. Россия тарихына кереп калган бабабызның исеме белән горурланабыз. Фамилиябез дә шул Шәрифулла бабайның исеменнән килә.

Шәрифулла бабай 1843-1917 елларда яшәгән. Аның бөтен тормышы армия белән бәйле. Ул заманнарда солдатлар 25әр ел хезмәт итә торган булганнар. Бабай да озак вакытка киткән, Александр патшаның (Александр II) кучеры булып хезмәт иткән. Үзе бик чибәр булган. Һәрвакыттта да башына түбәтәй киеп йөргәнгә, бер дә салмаганга, аның кушаматы Татарин булган.

Киноларга да кереп калган бабабыз. Кинода да аны Татарин дип атаганнар. «Семь покушений на Александра второго» дигән фильм бар. Шушы кинода Александр IIнең кучеры – безнең бабабыз турында да искә алына.

Шәрифулла бабай туган илгә тугрылыклы булган, Ватанын бар нәрсәдән якынрак күргән. Шуның өчен патша аңа Георгиев тәресе (крест) тапшырган. Патша бабайга бер авыл да бүләк иткән. Шунысы кызганыч: моны раслый торган документлар янгында янып беткән.

23 елдан соң бабай армия хезмәтеннән туган авылына баеп кайткан, аңа бик күп акча биргән булганнар. Ул акчаларның берсен дә тотмыйча, чүлмәкләргә салып, мич башына куеп торган.

Эшчән, сүз тыңлаучан булганга күрә, аны авылда да бик яратканнар. Бервакыт аларның авылында янгын чыга һәм ярты авыл өе янып бетә. Байларның да өе яна башлый. Шушы янгын вакытында акча салып торткан чүлмәкләре ватылган һәм авыл халкы бөтен байлыкны үзенә алган. Янгын вакытында бабай чүлмәкләре турында уйламаган, аңа балаларын, терлекләрен коткарырга кирәк булган. Документлары көлгә әйләнгән. Шулай итеп, армия хезмәтеннән шактый гына баеп кайткан бабабыз бернәрсәсез калган. Бабайның нәсел җебенә килсәк, тагын шуны беләбез: патшага хезмәт иткәндә, ул бер урыс хатынына өйләнгән һәм аларның улы туган. Ул малайның Александр исемле оныгы бар, хәзер Мәскәүдә яши. Туганнан туган абыебыз Айдар аның белән интернет аша табышып аралаштылар. Шәрифулла бабай Минзәлә районы Дәвек авылында 74 яшендә гүр иясе булган, кабере шул авыл зиратында. Шәрифулла бабайның оныгы Фәхерниса әби хәзерге вакытта Дәвек авылында яши. Аңа 93 яшь. Ул – авылның иң өлкән кешесе.

Шәрифулла бабайның икенче оныгы Гарифә безнең әбиебез була инде. Ул 1931 елгы. Кешеләргә массажлар, дару үләннәреннән төнәтмәләр ясый иде. Психолог кебек, һәр кешегә үзенең киңәшләрен бирә иде. Күп укыган, шигырьләр, бәетләр чыгарган, гарәпчә укый белгән, җырлап-биеп, туйлар алып барган. Гомумән, бик оста, җитез булган ул безнең әби.

Әмирулла бабабыз – әниебезнең әтисе ятим үскән. Балта остасы булган, өйләр салган. Пермьгә шахта эшенә киткән. Акча эшләп кайткач, балаларын укытыр өчен, Чаллыга күченгәннәр. Бөтен балалары да югары уку йортларын тәмамлап, химик, экономист, инженер, программист, табиб һөнәрләре үзләштергән.

Нәсел тарихыбыз белән кызыксынуыбыз дәвам итә.

Камилә һәм Диләрә ШӘРИФУЛЛИНАЛАР,
Казан шәһәре, Киров районы 4нче интернат-гимназиянең 10нчы сыйныф укучылары.

Көндәлекне мәктәп елларыннан ук яратам. Әниемне сөендергән «5»леләрем сандыгы иде бит ул. Көндәлекле мәктәп еллары күптән артта калса да, минә бишенче ел инде, уку елы башлангайда, көндәлек сатып алам. Юк, укучы балаларым өчен түгел, аларның бит хәзер электрон көндәлек. Үзем өчен!

Көндәлегем бар минем...

Ул көндәлекнең уңайлыкларын, кем әйтмешли, белмәгән генә белми. Шул белмәгәннәр өчен язуым да инде.

Көндәлекне, иске гадәт белән, 1 сентябрьдә башлыйм. Кем белән очрашасы, нәрсә эшлисе, кемгә шалтыратасы – барысын да шунда язып барам. Адреслар, телефон номерлары да шунда, кул астында гына. Барысын да хәтердә саклап булмый бит. Рус теле укытучыбыз Назыйф абый әйтмешли, «баш мие түп савыты түгел, барысын да тутырырга». Яшәлгән еллар да әзсез узмый, хәтерне саектыра. Ә болай җайлы, бер атнага, кайчак бер айга да план әзер, күз алдында. Берәр очрашуга чакырсалар, ризалык биргәнче, бу көнне ниләр планлаштырылган икән дип, иң элек көндәлегемне ачып карыйм. Үтәлгәннәренә «+» куеп барам, вакыты үзгәргәннәрне башка көнгә күчереп «арканлыйм». Дөрес, хәзер махсус көндәлекләр дә бар, ләкин алар бер көнне генә планлаштырырга мөмкинлек бирә, атна күз алдында тормый. Телефонда блокнот тотучылар да күптер, әмма миңа көндәлектән дә җайлысы юк. Баштарак өстәл өстендә мәктәп көндәлеген күреп, мине: «Эшләгән эшеңә билге дә куясыңмы?» – дип үчеклиләр иде. Чүлмәкчедән күрмәкче, миңа ияреп көндәлек башлаучылар, җайлы икәнен белгәч, хәзер авызларын да ачмыйлар.

Беркөнне яшь хезмәттәшемнең өстәлендә дә шундый мәктәп көндәлеге күргәч, тагын сөенеп куйдым. Артабыз, димәк. Тормышыбызны бераз гына булса да җиңеләйтү юлларын нишләп соң әле бер-беребезгә өйрәтмәскә ди. Беләм, «Тузга язмаганны язган инде шунда...» диючеләр дә табылыр. Андыйлар да сынап карасын.

Йолдыз ШӘРАПОВА.

Татарстан урманнарында аюлар арта

Элегрәк Татарстанда Киров өлкәсенә, Мари Эл һәм Удмуртия республикаларына чиктәш районнарда гына аюлар очрый торган булган.

Дамир БӘДРИЕВ

– Хәзер аюлар Мамадыш, Саба, Балык Бистәсе, Арча, Питрәч, Лаеш районнарында һәм Казан янәшәсендәге урманнарда да бар. Аларны аулау тыела, бу җәнлекләр сан ягыннан елдан-ел үрчиләр, – диде Татарстанның җәнлекләр дөньясы объектларын саклау һәм файдалану идарәсенең бүлек җитәкчесе Ринат Чиспияков «Татар-информ» агентлыгында узган матбугат конференциясендә.

Узган җәйдә Балык Бистәсе районындагы урманнарда кешеләр, ике метрдан озынрак еланга юлыгып, кәрҗин-капчыкларын ташлап качканнар.

– Республикада табигать салкын, кыш чоры бар. Шунлыктан ике метрлы еланнар бездә яши алмый, – дип шик белдерде моңа Ринат Чиспияков.

Аның сүзен 50 ел буе аучылык белән шөгыльләнүче Лев Груздев та куәтләде.

– Ике метрлы еланнар күргәнем булмады, ә республика урманнарында бер метрлы һәм аннан да озынрак тузбашлар, кара еланнар бар. Кара еланнарны үтерү тыела. Татарстанның җәнлекләр дөньясы, Урал яклары белән чагыштырганда, артык бай түгел. Шөкер, бүген аучылыкта таләпләр шактый катгый, – диде ул.

Татарстанның җәнлекләр дөньясы объектларын саклау һәм файдалану идарәсенең бүлек җитәкчесе Радик Мотахаров таныштырганча, узган ел 164 браконьер тотылган, аларга 945 мең сум штраф салынган. Аучылык чоры игълан ителгән көннәрдә генә аулау рөхсәт. Ау этләреннән файдалану тыела. Мылтыкка документ һәм аучылык хуҗалыгыннан рөхсәт булуы катгый шарт.

– Автотрассаларда урманнар аша узганда тизлекне киметү зарур. Узган ел транспорт чаралары 42 җәнлекне бәрдереп харап итте. Гаеплеләрдән ике миллион сум штраф түләтерелде, – диде Радик Мотахаров. – Һәвәскәрләргә Идел, Кама, Зөя кебек зур елгаларда ятьмә белән балык тотарга рөхсәт юк. Узган ел 4 300 ятьмә конфискацияләнде. Рөхсәтсез рәвештә җәнлек атсаң яки бәрдереп үтерсәң, 200 мең сумга кадәр штраф салына. Аучылык хокукы өч елга кадәр чикләнелә. Җәнлекләр дөньясына артык зур зыян салынган очракларда җинаять эше кузгатыла. Узган ел шундый 54 эш башкарылды. Гаепле кеше шартлы рәвештә ике елга кадәр ирегеннән мәхрүм ителергә мөмкин.

Ринат Чиспияков әйткәнчә, Татарстанда 28 февральгә кадәр җәнлекләрне исәпкә алу үткәрелә. Республика урманнарында, 2016 ел күрсәткечләре буенча, 6200 кабан дуңгызы, 7100 поши, 20 мең куян, 6 мең төлке, 90 мең кыр тавыгы исәпләнә.

– Татарстанда 66 аучылык хуҗалыгы эшли. Өч хуҗалык туристлык аучылыгын гамәлгә куярга әзерләнә. Ауга лицензияле һөнәри аучылар бригадасына кушылып чыгарга да була. Бригада составындагы һәр кешенең исем-фамилиясе язылган юл кәгазе алдан ук тутырылган булырга тиеш, – дип искәртте Ринат Чиспияков.

Республиканың дәүләт һәм муниципаль хезмәт күрсәтүләр порталындагы «Халык контроле» адресына рөхсәтсез аучылык белән шөгыльләнүчеләр, ягъни браконьерлар турында хәбәр җибәрергә мөмкин.

ЧАЙНВОРД



Нияз Бишбалта төзеде

«Җиләк-җимеш, яшелчәләр базары»

1. Җылылыкны ярата торган кузаклы үсемлек (орлыгыннан тәмләткеч ясыйлар).
2. Роза чәчәкләре семьялыгыннан җимеш бирә торган куак һәм аның түгәрәк сусыл җимеше.
3. Үсемлекләрнең, яшелчәләрнең тукланышын, үсешен тәэмин итә торган сабактагы яшел үсенте.
4. Үсемлекләргә җылылык һәм яктылык чыганагы.
5. Кара җимешле тәлгәш (ашарга ярый, дару ясала).
6. Тәме бик ачы була торган тамыразык.
7. Алмагачның хуш исле, татлы җимеше.
8. Калын кыяк яфраклы тропик үсемлек һәм аның җимеше.
9. Әчкелтем сары җимешле куак.
10. Актикән һәм аның җимеше.
11. Озынча сусыл җимешле яшелчә.
12. Тиз өлгерешле берьеллык яшелчә үсемлек.
13. Көньяк агачы һәм аның әчкелтем-баллы җимеше.
14. Карабодайчалар семьялыгыннан күпьеллык үләнчел үсемлекләр ыругы, яшелчә культурасы.
15. Кайбер үлән яки үсемлекләрнең сусыл, татлы вак җимеше.
16. Зур җимешле бакча үсемлеге.
17. Бакчада үстерелә торган зур яшелчә (кәҗәнең яраткан ризыгы).

Җаваплар.
1.Борыч **2.**Чия **3.**Яфрак **4.**Кояш **5.**Шомырт **6.**Торма **7.**Алма **8.**Ананас **9.**Сырганак **10.**Крыжовник **11.**Кыяр **12.**Редиска **13.**Анар **14.**Рәваҗ **15.**Җиләк **16.**Кабак **17.**Кәбестә.

Бөтен кызыклы мәгълүмат бер урында
www.shahrikazan.com

Ап-ак кышның кадерен белик!

Без шундый инде, эссе җәйдә – салкын кышны, ап-ак карлы кыш җитсә, эссе җәйне сагынабыз. Бүгенге көн белән яшәргә, һәр туар таңның, һәр көннең, һәр мизгелнең кадерен белеп, матурлыгын-рәхәтлеген күреп, булганына шөкер итеп яшисе дә яшисе бит югыйсә!

Инде кышның да бер генә ае калып бара. Һәр ел фасылының искиткеч матур мизгелләре бар бит аның! Башкалабызда гына да әллә никадәр шугалак ачылды, төрле күңел ачу мәйданнары эшләп тора. Бала-чагалар белән бергәләп, кар бабайлар, төрле җәнлекләр ясыйк, бит очларын алсуландырып, рәхәтләнеп тау шуыйк, чаңгыда, тимераякта йөрик. Дөнья матур, дөнья киң бит ул!

Начарны күрим дисәң – начарны күрергә, яхшылыкка омтылыйм дисәң, яхшыга тартылырга мөмкин. Узган атнада без дә гаиләбез белән бергәләп Горький ял итү паркына бардык. Мин чаңгыда йөргән арада, балалар әтиләре белән таудан шуып рәхәтләнделәр. Аннан соң балалар кафесына кереп, тамак та ялгап алдык. Гаилә без белән саф һавада ял итү балаларга да, үзебезгә дә бик ошады. Киләчәктә гаилә дусларыбыз белән тагын җыйналырга кирәк, дип кайттык. Мәш килеп, хәлдән таеп арып кайтканнан соң, балалар тәмләп, изрәп йокыга талдылар.

Кызганыч, хәзер балалар интернет «тоткыннары»на әйләнде шул. Без кечкенә чакта авыл урамнары бала-чага тавышыннан гөж килеп тора иде. Мәктәптән кайткач, тау шуарга бара идек. Чана булмаганда да, капчыкка салам тутырып, и рәхәтләнә идек тә соң! Тау шуа торган калкулыклар ялтырап торыр иде...

Галия СИТДЫЙКОВА,
Казан.

Яңа елдан ОСАГО полисын алуда үзгәрешләр

ОСАГО полисларын бирүгә лицензиясе булган барлык иминият компанияләре 2017 елның 1 гыйнварыннан Россия Федерациясе территориясендә ОСАГО килешүләрен электрон рәвештә төзергә тиеш.

ОСАГО турындагы законга үзгәрешләр Россия Банкы тарафыннан кертелде. Электрон полисларны ирекле сату 2015 елның 1 июленнән гамәлгә ашырыла башлаган иде. Бу вакыт аралыгында берничә йөз мең электрон полис сатылган.

Полисны, өйдән чыкмыйча да, иминият компаниясе сайтыннан алырга мөмкин. Иминият оешмасы сайтына Россия автоиминиятләштерүчеләр берлеге сайты аша гына керергә була. Агентлар, арадашчылардан алынган электрон полислар законсыз дип санала. Компаниянең ОСАГО бирүгә лицензиясе барлыгын Россия Банкы рәсми сайтында (www.cbr.ru) яки Россия автоиминиятләштерүчеләр берлеге (РСА) сайтында (www.autoins.ru) карарга мөмкин.

Бердәм мәгълүмат базасына кертелмәгән, ягъни әле генә машина йөртү таныклыгы алучылар да электрон полис рәсмиләштерергә хокуклы.

Электрон полис алу бик гади. Аның өчен паспорт, машина йөртү таныклыгы, ПТС һәм өч елдан артыграк кулланылган автомобильләргә диагностика картасы кирәк.

ОСАГО полисын электрон рәвештә алу өчен, иминият компаниясе сайтында теркәлү узарга һәм логин, пароль алырга кирәк. Логин һәм пароль электрон почта, СМС-хәбәр яки офиска мөрәҗәгать иткәндә бирелә. Компаниянең рәсми сайтында теркәлү узгач, электрон формада гариза язу мөһим.

Иминият компаниясе электрон полис өчен түләүне үз рәсми сайтында банк карталары ярдәмендә тормышка ашыру мөмкинлеге булдырырга тиеш. Электрон полис компания сайтына теркәлү узганда күрсәтелгән электрон почтага яки сайттагы «шәхси кабинет»ка җибәрелә. Автомобиль хуҗалары ОСАГО полисын кәгазьгә чыгартып алырга, кирәк вакытта, ЮХИДИ хезмәткәрләренә күрсәтергә тиеш.

ОСАГО килешүен электрон рәсмиләштергәндә сораулар туса, РФ Үзәк банкының Идел-Нократ баш идарәсе ТР буенча милли банкы бүлегенә язма мөрәҗәгать юллый аласыз. Адресы: 420013, Казан шәһәре, Бауман урамы, 37. Шулай ук Россия банкы сайтында (www.cbr.ru) электрон форма тутырырга мөмкин.

Мөрәҗәгатькә мобиль җиһаз яки компьютер экраныннан скриншот-фото теркәү мөһим. Фотода иминият компаниясе сайтына мөрәҗәгать итү көне һәм вакыты булу зарур.

КАЗАНСКИЙ ЗАВОД СИЛИКАТНЫХ СТЕНОВЫХ МАТЕРИАЛОВ
КИРПИЧ от 8,87 р./шт.
5-707-909
5-719-259
www.kzssm.ru
подробности по телефону
ГАЗОБЕТОН от 57,60 р./шт.
ЖБИ изделия
ОТГРУЗКА КРУГЛОСУТОЧНО
Реклама

АФИША
23 – 29 ГЫЙНВАР

Г.КАМАЛ ИСЕМЕНДӘГЕ ТАТАР ДӘҮЛӘТ АКАДЕМИЯ ТЕАТРЫ
(ТАТАРСТАН УРАМЫ, 1)

24 гыйнвар «Исәнме, улым!» (Б. Абдураззоков)
Башлана: 19.00
Билет бәясе: 300-350 сум

25 гыйнвар «Бабайлар чуагы» (И.Зәйниев)
Башлана: 19.00
Билет бәясе: 200-1200 сум

26 гыйнвар «Галиябану» (М.Фәйзи)
Башлана: 19.00
Билет бәясе: 200-1200 сум

27 гыйнвар «Әрем исе» (И. Зәйниев)
Башлана: 19.00
Билет бәясе: 200-1200 сум

28 гыйнвар «Хуҗа Насретдин» (Н. Исәнбәт, С.Ваннус)
Башлана: 18.00
Билет бәясе: 200-1200 сум

29 гыйнвар «Диләфрүз - Remake» (Т.Миңнуллин)
Башлана: 12.00
Билет бәясе: 150-1000 сум

29 гыйнвар «Искән җилләр көенә» (З. Хәким)
Башлана: 18.00
Билет бәясе: 200-1200 сум

Г.КАРИЕВ ИСЕМЕНДӘГЕ КАЗАН ТАТАР ДӘҮЛӘТ ЯШЬ ТАМАШАЧЫ ТЕАТРЫ
(ПЕТЕРБУРГ УРАМЫ, 57)

25 гыйнвар «Ширбәт ае» (А.Попов, Х.Ибраһимов тәрҗемәсе)
Башлана: 18.30

27 гыйнвар «Улыбыз өйләнә, без аерылышабыз» (И.Юзеев)
Башлана: 18.30
Билет бәясе: 150-200 сум

К.ТИНЧУРИН ИСЕМЕНДӘГЕ ТАТАР ДӘҮЛӘТ ДРАМА ҺӘМ КОМЕДИЯ ТЕАТРЫ
(ГОРЬКИЙ УРАМЫ, 13)

24 гыйнвар «Өзелгән яфраклар» (Р.Габделхакова)
Башлана: 18.30

25 гыйнвар «Мәхәббәт чишмәсе» (И.Мәхмутова)
Башлана: 18.30

26 гыйнвар «Беренче мәхәббәт» (И.Гали)
Башлана: 18.30

27 гыйнвар «Ефәк баулы былбыл кош» (А.Гыйләҗев)
Башлана: 18.30

28 гыйнвар «Ак тәүбә, кара тәүбә. Безнең көннәр» (Т.Миңнуллин)
Башлана: 17.00

28 гыйнвар «Әллә язмыш, әллә ялгыш...» (автор – Н.Нестерова, И.Хафизов тәрҗемәсе)
Башлана: 17.00
Билет бәясе: 250-600 сум

ТАТАР ДӘҮЛӘТ «ӘКИЯТ» КУРЧАК ТЕАТРЫ
(ПЕТЕРБУРГ УРАМЫ, 57)

25 гыйнвар «Бүре җиләге» (Р.Зәйдулла)
Башлана: 11.00

26 гыйнвар «Волшебник изумрудного города» (А.Волков)
Башлана: 11.00, 13.00

27 гыйнвар «Буратино» (А.Толстой, инсц. Р.Давыдова)
Башлана: 11.00, 13.00

28 гыйнвар «Не хочу и не буду»
Башлана: 10.00

28 гыйнвар «Кыш бабай кучтәнәчләре» (Н.Абрамцева)
Башлана: 11.00, 13.00

29 гыйнвар «Идет Коза рогатая» (М.Протасова)
Башлана: 10.00

29 гыйнвар «Чебурашка маҗаралары» (Э.Успенский, В.Фечина инсц.)
Башлана: 11.00, 13.00
Билет бәясе: 200-300 сум

Г.ТУКАЙ ИСЕМЕНДӘГЕ ТАТАР ДӘҮЛӘТ ФИЛАРМОНИЯСЕ
(ПАВЛЮХИН УРАМЫ, 73)

27 гыйнвар «Аргентино танго-сы» «TangoenVivioorchestra» төркеме башкаруында
Башлана: 18.30
Билет бәясе: 300-1000 сум

29 гыйнвар «Пошалым чаналары -2017» Рөстәм Закиров концерты
Башлана: 17.00
Билет бәясе: 500-1000 сум

«ШӘҺРИ КАЗАН» РЕДАКЦИЯСЕНЕҢ КҮРГӘЗМӘЛӘР ЗАЛЫ
(ЧИСТАЙ УРАМЫ, 5)

Фотохәбәрчеләр Илдар Мөхәммәтҗанов белән Шамил Абдюшевның «Чор һәм шәхес» дип аталган фотокүргәзмәсе эшли.
Керү ирекле (эш көннәрендә)

Иске самавыр

Заманында, җәй көннәрендә ял итәргә урын булыр дип, Арча районының бер авылында йорт алган идек без. Иске йорт. Урын матур, табигать матур – ял ит рәхәтләнеп. Шактый озак хуҗа булдык без ул йортта. Бик күңелле булып истә калган ул еллар.

Шул йортның чормасында казынганда, мин анда бер самавыр таптым. Зур, җиз самавыр. Чормадан алып төшеп чистарткач исем китте – бу бит без кечкенә чакта үзебезнең әби күршедәге Әсма әби белән сәгатьләр буе чәй эчеп утыра торган самавырның игезәге! И-и-и ул самавыр тирәсендә сөйләшелгән серле сүзләр, и аның тәмле итеп чыжлап утыруы, и ул самавыр чәенең тәмлелеге...

Авылдагысы күптән каядыр җуелган булганга, Арчаныкын кадерләп, Казандагы фатирга алып кайтып куйдым. Тик... Шәһәр фатирында иске самавырга урын табу уңайсызрак булып чыкты. Кухняга куйган идем, хатын, интерьерны боза, дип, аннан алдыртты, йокы бүлмәсе – шулай ук урыны түгел. Бермәлне ул балконга урнашты. Анда да йә абынасың, йә бәрләсең... Кыскасы, самавыр фатирда ничектер ятимгә әйләнде. Бермәлне өч бүлмәле фатирда аңа бөтенләй урын табылмый башлады.

Шул көннәрдә безгә тәрәзә алыштыручылар килде. Өлкәнрәге самавырны күрде дә ябышты бит: «Сат та сат». Өч мең тәңкә бирәм, ди. Әби белән Әсма карчык искә төштеләр. Сатмадым.

Шулай ярым ятим килеш тагын ике еллап яшәде бездә Арча самавыры. Кунакка дуслар килде. Боларның да самавырга исе китте. Шул ук сүз – сат!

Биш мең бирәләр! Юк, сатмадым. Тагын берничә ел вакыт үтте. Тормышлар бераз үзгәреп, финанс хәлләре дә ничектер киеренке булып китте. Самавырга тагын хуҗа табылды. 12 мең бирәләр. Акча да кирәк тә бит... Балконда торган самавырга карыйм. Аның ышыгында мәрхүмә әбием белән Әсма карчык чәй эчеп утыра кебек. Ничек сатыйм инде мин аны?! Әбиемнең истәлеген саткан кебек була бу! Шулай итеп, калды самавыр өйдә. Күңел тулганда, балконга аның янына чыгып утырам. Ничектер әбием рухы ярдәм иткән кебек була. Чынлап.

Соңгы хәбәрләр буенча, җиз самавырларның бәясе 20 меңгә җиткән, имеш. Юк, сатмыйм барыбер.

Илфак ШИҺАПОВ.

Ике күрше

Ике күрше яшәгән. Кыш җиткән. Кар явып узган. Беренче күрше иртән-иртүк торып кар көрәргә чыккан. Озак кына маташканнан соң күршесенә күз салса, тегенең капка алды тап-такыр икән.

Икенче көнне дә кар яуган. Бу юлы беренче күрше бер сәгатькә алданрак чыгып эшкә тотынган. Шыбыр тиргә батып, карны көрәп куйган да, тантана белән, күрше йортка күз ташлаган. Сездән алданрак көрәп куйдым, янәсе. Ә күршенең капка алды – такыр.

Өченче көнне дә кар яуган. Беренче күрше бу юлы, урамга чыгу белән, күршеләренә караган. Ә аларның инде юл салынган икән. Бу кеше түзмәгән, күршесенә кереп сорарга мәҗбүр булган:

– Карале, күрше, кай арада кар көрәргә өлгерәсең син, ә?

Күршесе башта берни аңламаган, ә аңлагач, көлгән генә:

– Көрәмим мин аны беркайчан да. Дуслар килә, шулар таптап бетерә.

ТАШКА БАСКАН

✓ Хатының: «Тавык» – дип тиргәүче ирләр, Яңа ел белән!

✓ Уналтынчы катка йөк күтәреп җәяү менгәндә, «начар лифтер» сүзенә йөздән артык синоним табып була.

✓ Иртән смс килде: «Абонент кабат элемтәдә. Сез аңа шалтырата аласыз!» Шалтыратмыйм. Соң инде. Айныдым.

✓ Кутузов Мәскәүне яндырган – ә герой. Мин котлетны гына яндырдым, шундук – беткәнбаш.

✓ Ул, ниһаять, акылына килде. Тик акылы танымады. Бу кешене аның күргәне юк иде.

✓ Хәмернең беренче шешәсе генә кыйммәт тора, калганы – арзан...

✓ Җилкәдә утыру өчен аякларны аерырга кирәк.

✓ Сөйләргә оят булган нәрсәләрне искә алу рәхәт.

✓ Дини кешенең ике юанычы бар: гөнаһ кылу һәм тәүбә итү.

✓ Вакытында әйтүгә караганда, вакытында дәшми калу кыенрак.

✓ Чама хисе чама белән бирелгән.

Шәһри Казан

ИНДЕКСЛАР
П2395 (3 тапкыр чыга)
П2430 (пәнҗешәмбе саны)
П2419 (оешмалар өчен)
www.shahrikazan.com

ГАМӘЛГӘ КУЮЧЫ (НӘШЕР ИТҮЧЕ) – «ТАТМЕДИА» АҖ
«ТАТМЕДИА» АҖ ФИЛИАЛЫ ҖИТӘКЧЕСЕ – БАШ МӨХӘРРИР ГӨЛНАРА ИЛЬЯС кызы САБИРОВА.
ЧЫГАРЫЛЫШ ӨЧЕН ҖАВАПЛЫ – РАСИХА ГАБДЕЛБӘР кызы ИСМӘГЫЙЛОВА.
© Газетада басылган язмаларны файдалану, шулай ук өзекләр китерү өчен, «ШК» редакциясеннән язмача рөхсәт алу мәҗбүри. Редакциянең фикере авторларның фикере белән аваздаш булмаска да мөмкин. Редакциянең рәсми оешмаларда юллаучы булып йөрү мөмкинлеге юк. Кульязмалар рецензияләнми һәм кире кайтарылмый. Реклама һәм игъланнардагы мәгълүматларның дөреслеге өчен аны бирүчеләр үзләре җаваплы.
РЕКЛАМА ХЕЗМӘТЕ
Тел: (843) 562-50-12,

ХАТЛАР БҮЛЕГЕ
Тел: (843). 562-50-03,
E-mail: shahri-kazan@tatmedia.com

НӘШРИЯТ
«Татмедиа» АҖ
420097, Казан, Академия ур., 2

16+
Сатудагы бәясе ирекле

Бу санның тиражы – 1551. Гомуми тираж – 5687.
Республика матбугат һәм массакүләм коммуникацияләр агентлыгы ярдәме белән чыгарыла.
Заказ 666. Газета Элемтә, мәгълүмати технологияләр һәм массакүләм коммуникацияләр өлкәсендә күзәтчелек итү буенча Федераль хезмәттә (Роскомнадзор). 2012 елның 27 августында ПИ №ФС77-50970 нче теркәлү таныклыгы алды. Газета атнага 3 тапкыр – сишәмбе, пәнҗешәмбе һәм җомга көннәрендә чыга. График буенча бу санга 17 сәгатьтә кул куелырга тиеш. Кул куелды – 17 сәгатьтә.

РЕДАКЦИЯ АДРЕСЫ
420066, Казан,
Чистай ур., 5 нче йорт
Тел.: (843). 562-50-12,
факс: (843). 562-50-07

БАСМАХАНӘ
420066, Казан, Декабристлар ур., 2 нче йорт.
«ТАТМЕДИА» АҖ филиалы «Идел-Пресс» полиграфия-нәшрият комплексы